Җырлы-биюле уеннар күп гасырлар дәвамында йола бәйрәмнәре вакытында зурлар тарафыннан уйналып килгән һәм соңга таба нәниләр репертуарына күчкән.

Балалар уеннарының иң таралган бер төре – тамашалы (драма) уеннар. Ул нәниләр психологиясе үзенчәлегеннән килә. Нәниләр әйләнә-

тирәлектән күп тәэсирләр алсалар да, аларны сүз белән тулаем әйтеп бирә алмыйлар. Шунлыктан үзләре күргән нәрсәләрне театрлаштырырга, уйлап бирергә тырышалар.

Татар халкының уеннары милләтебезнең эстетик карашларын, милли характерын, генетик тамырларын ачыграк төсмерләргә мөмкинлекләр ача. Икенче яктан ул халыкның рухи тормышын, көнкүрешен матурлык кануннары нигезендә оештыруның мөһим чаралары да булып тора.

**Йомгаклау**

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны милли мәдәнияткә җәлеп итү бүген бик актуаль мәсьәләләрнең берсе. Чөнки һәр халык үз традицияләрен һәм үзенчәлекләрен саклап кына калмый, ә тарихи милли йөзен һәм үзенчәлеген югалтмас өчен аларны киләчәккә күчерергә омтыла.Нәкъ менә сабый чакта, дөньяга караш формалашканда баланың үз милләтенә, диненә, гореф-гадәтләргә мәхәббәт орлыклары чәчеп калдыру кирәк

Безнең балалар бакчасында балаларга милли тәрбия бирү буенча шактый эш алып барыла. Без шөгыльләр вакытында, күңел ачу иртәләрендә, саф һавада татар халык уеннарын киң кулланабыз. Балалар да халык уеннарын бик яратып уйныйлар. Бакчабызда үткәрелеп килгән «Сөмбелә», «Каз өмәсе», «Нәүрүз», «Сабантуй», «Аулак өй» татар халык милли бәйрәмнәре җырлы-биюле музыкаль уеннардан башка үтми. «Күрсәт әле үскәнем», «Төсле яулыклар», «Зәңгәр чәчәк», «Куш кулым», «Эх, зилем зиләле», «Түбәтәй» җырлы– биюле татар халык уеннарын балалар аеруча да яратып башкаралар.

Шулай итеп, мәктәпкәчә яшьтәге балаларны үз халкының мәдәни мирасына җәлеп итү балаларда татар халкының тарихы, гореф-гадәтләре, мәдәнияте турында белемнәр формалаштырырга мөмкинлек бирә.

## КУЛЬТУРНЫЕ НАСЛЕДИЯ НАРОДОВ РОССИИ (ПОВОЛЖЬЯ)

***Зарипова Альбина Ильгизаровна,***
*учитель-логопед,*
***Шамилова Гульназ Саматовна,***
*воспитатель МБДОУ №112 г.Казани: РТ*

Воспитывать в детях толерантное отношение к другим народностям-одна из важных задач работы детского сада. Детский сад-это поликультурной мир, где каждый ребенок, какой национальности он ни был, каждый является представителем своего мира, традиций, культуры. И

маленький татарин, и маленький чуваш, и маленький русский должны иметь представление о культуре, быте, жизни своего и другого народа, доступное их возрасту.

Приобщение дошкольников к социальной действительности, воспитание маленького гражданина – актуальная проблема современного образования. Важным аспектом этой проблемы является поликультурное воспитание дошкольника. Поликультурное воспитание понимается нами как воспитание ребёнка на культуре народов региона, где проживает воспитанник, с приоритетом для него культуры его национальности.

На основании ФОП ДО цель воспитания в ДОО – это личностное развитие каждого ребенка с учетом его индивидуальности и создание условий для позитивной социализации детей на основе традиционных ценностей российского общества. Выделены следующие направления воспитания: патриотическое, духовно– нравственное, социальное, познавательное, физическое и оздоровительное, трудовое и эстетические направления воспитания. Поликультурное воспитание позволяет воздействовать по всем направлениям воспитания.

Ежегодно в начале учебного года старший воспитатель разрабатывает календарный план воспитательной работы. Этот план рассматривается и утверждается на педагогическом совете. В течение учебного года, в рамках календарного плана воспитательной работы, мы проводили различные мероприятия с детьми, с родителями с целью приобщения культурному наследию народов Поволжья. Например: для детей и родителей был объявлен конкурс «Культура в чемодане». Каждая возрастная группа оформила чемодан национальными праздниками народов Поволжья. В конкурсе приняли участие такие творческие работы, как «Сабантуй» – татарский национальный праздник, «Соварни» – чувашский праздник, «Масленица» – русский праздник, «Кугече» (Пасха) – марийский праздник, «Гырон быдтон» – удмуртский праздник, «Каргатуй» – башкирский праздник. С помощью Яндекс Формы родителям, педагогам была представлена возможность проголосовать за самый оригинальный чемодан. Таким образом, были определены победители конкурса. Старшим воспитателям был разработан сайт «Народы Поволжья», где размещена информация о продуктах питания, о национальных костюмах, о песенно-хороводных играх, о праздниках, об украшениях народов Поволжья. На каждый чемодан прикреплен QR-код, сканируя с помощью мобильного устройства родители открывают сайт и получают подробную информацию о культурных ценностях народов.

С воспитанниками старших и подготовительных групп и с музыкальным руководителем был поставлен танец «Национальные праздники

народов Поволжья», где дети представили такие праздники, как татарский праздник «Сабантуй», русский праздник «Масленица», удмуртский праздник плуга «Акаяшка», чувашский праздник сбора урожая «Чукleме». Танец объединил в себе дружбу народов, единство нашей страны.

Ежегодно для детей организуем праздник «Халыклар дуслыгы-дружба народов», в рамках которого каждая возрастная группа представляет одну песенно-хороводную игру. Костюм, элементы костюма изготавливают родители. Таким образом, родители наших воспитанников не являются пассивными участниками образовательных отношений, а напротив, активно включаются в образовательный процесс, сотрудничают с образовательной организацией.

После проведенного праздника для детей и родителей была организована выставка «Дружба народов – Халыклар дуслыгы». Выставка состоит из плакатов, каждый из которых оформлен фотографиями, описанием игр, которые были продемонстрированы на празднике. К плакату прикреплен QR -код, сканируя с помощью мобильного устройства родитель сможет увидеть видеофрагмент этого праздника-песенно-хороводную игру. В рамках праздника были изучены: татарская народная игра «Кульяулык алыш», русская народная игра «Земелюшка чернозем», чувашская народная игра «Кояш һэм Ай», удмуртская народная игра «Кем олгер» ,марийская народная игра «Яулык кайда», башкирская народная игра «Тирмә».

Также в приобщении детей и родителей к культурному наследию народов Поволжья мы применяем авторскую рабочую тетрадь «Карусель дружбы-Дуслык каруселе». Рабочая тетрадь включает в себя 12 мероприятий, которые организуются в течение учебного года. К каждому мероприятию предусмотрена предварительная работа в форме теоретической части и игровых заданий для детей.

Накопленный опыт многократно демонстрируется в международных, всероссийских, межрегиональных, республиканских, городских и районных семинарах, методических объединениях.

Воспитанники старших и подготовительных групп. В национальных костюмах, совместно с педагогами исполняют песню «Дуслар куп булсын» (автор: Булат Ибрагимов, музыка: Лейсан Закирова). Гимн нашего детского сада, который назван «Дуслык» (Дружба).

Только целенаправленная совместная работа педагогов и родителей приводит к успеху. Мы считаем, что регионально-этническую направленность воспитания детей необходимо рассматривать как ведущую деятельность педагогов по организации педагогического процесса в дошкольном образовательном учреждении.

# ТРАДИЦИИ ТАТАРСКОГО НАРОДА

***Ибрагимова Алина Газизяновна,***
*воспитатель группы продлённого дня*
*МБОУ «Гимназия №1 имени Ч.Т.Айтматова г.Кукмор» РТ*

Кто не знает татар? Конечно же татар знают не только в России, но и в Турции, Японии, Австралии, Китае и в других странах. Это представители огромного тюркского этноса. Имея богатую историю, татары также обладают уникальной культурой. Они испокон веков хранят и чтят традиции, передавая их молодому поколению. Открыть для себя культуру татар помогут традиции и блюда.

1. Татары настолько гостеприимный народ, что никого не оставят голодным. И накормят, и угостят самым популярным татарским напитком– чаем. Наливают его в пиалы в горячем виде. С XIX века без чая не обходится ни один праздник, в том числе и свадьба.

2. Сабантуй. В переводе Сабантуй означает «праздник плуга». Славится этот праздник концертами с народными песнями и танцами, ярмарками национальных товаров, народными спортивно-развлекательными программами. Соревнования по борьбе, бег в мешках, бег с веслами -отличительные игры этого праздника

3. Никах. Традиционная татарская свадьба не обходится без мусульманского обряда никах, который проводится дома или в мечети в присутствии муллы. Праздничный стол состоит из татарских национальных блюд: губадия, чак-чак, катык, балеш. Жених надевает тюбетейку, невеста длинное платье с закрытыми рукавами, покрывает платком волосы. На никах жених должен дать невесте махр. Махр– обязательная выплата женихом своей невесте. Это может быть, как ювелирное украшение, так и имущество. Чем дороже махр, тем больше муж будет ценить свою жену.

4. Каз өмэсе. Древний татарский праздник, который переводится как «гусиное перо», или «праздник гуся». Обычно празднуется поздней осенью. Когда-то жители татарских сел проводили коллективную обработку гусиного мяса, пера и пуха.

По традиции в этот день заготавливают впрок гусиное мясо и щиплют пух – на подушки, которые пойдут на приданое невестам. Сегодня во время праздника татары устраивают гулянья, посиделки, общаются и исполняют народные песни.

5. Чак-чак это символ солнца и гостеприимства, которым татары до сих пор угощают гостей. Мука, яйца, молоко, масло и мед все, что нужно для вкусного чак-чака. Подается чак-чак и в особенные дни.

6. Өчпочмак это треугольные пирожки с начинкой из мяса и картофеля. Интересно то, что өчпочмак заменяет сразу два блюда-и первое, и второе. Этот пирожок с наваристым бульоном покорил сердце многих.

7. Ураза бәйрәме. Приходится он на девятый месяц по календарю мусульман. На этот период выпадает пост, который должны выдержать истинные мусульмане. Это вызывает укрепление их духа и милость Аллаха. Пост мусульман значительно отличается от православного мира. Есть кушанья, пить напитки нельзя на протяжении светового дня.

8. Карга боткасы. Как только появлялись первые ручьи, прилетали птицы, устраивали праздник. С раннего утра дети пели песни, ходили из дома в дом и собирали продукты. Затем все собирались и готовили на костре кашу для всего населения. Во время процесса люди играли в различные игры, водили хороводы. Такая каша никого не оставит равнодушным. Готовят ее из того, что есть в каждом доме.

Татары – древний народ с интересной многовековой историей. Главной чертой татарского народа является почтение к своим предкам, обычаям. Они сохранили свои корни благодаря точному следованию всем ритуалам, канонам.

## КЫЗЫЛ ТАУ АВЫЛЫ ХАЛКЫНЫҢ КҮҢЕЛ БИЗӘКЛӘРЕ

***Мирзаханова Эльмира Василовна,***
*Түбән Өскебаш авылы төп гомуми белем бирү мәктәбенең тарих, җәмгыять белеме укытучысы*

Нинди генә исеме юк анын: Кызыл Тау, Красные Горы, Красная Гора, Миләтле баш, Биләтле башы. Түбән Өскебаш авыл җирлегенә кергән әлеге авылның тарихын өйрәнеп, анда яшәүче кешеләрнең гореф – гадәтләрен язып калдырырга уйладым.

Кызыл Тау авылының барлыкка килүе чама белән 1650 нче елларга туры килә. Элек авыл урынында бик калын урман һәм сулык булган. Бу тирәдә кешеләр яшәгәнен суда агып килгән йомычкадан белгәннәр. Керәшеннәр барлыкка килгәнче бу төбәктә чирмешләр яшәгән. Аларның кайберләре вафат булган, кайсылары күчеп киткән. Шулай итеп, чирмеш нәселләре бөтенләй беткән. Авыл буласы җиргә Албай керәшене яшәү урыны эзләп килгән. Албай керәшеннәре үрчегәннәр. Алар өч нәселгә җиткәннәр: беренче нәсел Симуш дип аталган. Икенче нәсел Тәмтеләр, өченчесе Асап нәселе булган. Шулай итеп керәшен халкы арткан. Бүгенге

көндә Кызыл Тау авылында яшәүче керәшеннәр дә шул нәселләргә барып тоташа.

Агачларны кискәндә тау башында киселмичә калган нарат агачы утыра. Авыл белән бер яшьтә ул изге карт нарат! Халык тырышып йортлар җиткергән. Алан түрендә үз көчләре белән дегет агызырга өй җиткергәннәр. Нарат утыны ягып, дегет агызганнар. Ул өйләрнең нигезе әле дә саклана, чокырланып тора. Аннан ерак түгел чишмә дә бар. Ул чишмәне Сапый бабай казып чыгарган, шуңа күрә Сапый чишмәсе, дип атала. Әлеге Изге чишмә гомер буе кешеләрне шифалы суы белән туендырып торган. Шофёрлар да, игенчеләр дә, юлаучылар да изге чишмәнең саф суын эчеп, ял итеп китәләр.

Ә менә Кызыл тау исеме, мөгаен, авыл башындагы тауларның кызгылт төстә булуыннан килеп чыккандыр, дип сөйлиләр.

Кызыл тау авылы тарихы архив документарында да чагылыш тапкан. «1680 елдан мәгълүм; 1954 елга кадәр рәсми исеме – Югары Биләтле. Биләтле исемле елга шушы авылдан башлангычын ала. XVIII йөз – XIX йөзнең беренче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә. Бу чорда халыкның төп шөгыле – игенчелек һәм терлекчелек, шулай ук киез итек басу кәсепчелеге тарала. XX йөз башында авылда чиркәү-приход мәктәбе, тимерче алачыгы, 2 вак-төякләр кибете эшли».Халык телендә аларны керәшеннәр, керәшен татарлары, дип йөртәләр. Төбәгебездә татарлар һәм керәшеннәр дус һәм тату яшиләр, чөнки телләребез бер, тик диннәребез генә төрле.

Яңа керәшеннәр XVIII-XIX гасырларда гына христиан динен кабул итәләр һәм аларның күпчелек өлешен ул вакытта чувашлар, марилар, удмуртлар тәшкил иткән. Шул көннән алып хәзерге вакытка кадәр күп сүзләр, йолалар, гореф – гадәтләр югалган. Аларның бары тик күпмедер өлеше генә көнкүрештә кулланыла һәм бу зур проблемаларның берсе булып тора.

Гасырлар дәвамында табигатьтәге еллык үзгәрешләргә, бабаларыбызның хуҗалык эшләренә һәм тормыш-көнкүрешенә бәйле рәвештә күп төрле йолалар барлыкка килгән һәм буыннан-буынга күчеп камилләшкән, искергәннәре кулланыштан чыккан.

Керәшеннәрдә яшәп килгән йола һәм бәйрәмнәрен үткәрү вакыты христиан календаре бәйрәмнәренә туры китерелгән.Аларның исемнәре татар теле үзенчәлекләренә яраклаштырып, русча йөртелгән. Шуңа күрә керәшен татарларының бәйрәмнәре рус халкыныкына охшаш. Ә йола, гореф-гадәтләре башкача. Керәшен халкының барлык башка милләтләрдән бер аерымлыгы бар: аларда һәрбер мәҗлестә, ниди дә булса выкыйгада җырлар җырлыйлар. Тик мәгънәсенә туры килешле буларак.

Керәшеннәрдә ел фасылларына караган, табигать күренешләренә бәйле рәвештә үткәрелә торган төрле йолалар, гореф-гадәтләр бик кызыклы. Борынгыдан килгән ышануларга нигезләнгән йолалар, күмәкләп, бөтен авыл халкы катнашында үткәрелә торган булган. Элекке гореф-гадәтләр, бәйрәмнәр, мәсәлән, нардуган уеннары, бәрмәнчек, тройсын яки каен башы бәйләү («яфрак бәйрәме» дип әйтелә), питрау һәм башка бәйрәмнәр үзенчәлекле җырлар, такмаклар белән уздырылган. Христиан бәйрәмнәре чиркәү календаре буенча уздырылса да, аларда динилек бөтенләй диярлек чагылмый, күбрәк борынгыдан килгән халык йолалары өстенлек алган. Кызганычка каршы, ул борынгы йолалар һәм йола җырлары хәзерге вакытта онытылып баралар, аларның матурларын яңартып, авылларга ямь өсти торган итеп, халыкка кире кайтару зарурлыгы нык сизелә. Кызыл Тау авылы керәшеннәре билгеләп үтүче бәйрәмнәр: Пыкрау, Нардуган, Раштуа, Кач ману, Май чабу, Бәрмәнчек, Оло көн (Пасха), Симек, Тройсын, Питрау, Элҗен.

Соңгы елларда халыкның туган җиренә, туган теленә, үткәненә, мәдәниятенә игътибары артканнан-арта бара. Бу үзгәреш йола һәм бәйрәмнәрне үткәрүгә, онытылганнарын торгызуга һәм яңартуга китерә. Буыннан-буынга күчеп килгән, бу рухи байлыкларыбыз -бүгенге көннәрдә дә безнең тормышыбызның, яшәешебезнең бизәге.

Татарстан халыкларының үзара дус, тату яшәве – бөтендөнья өчен толерантлык үрнәге булып торуын күрсәтә. Халыклар арасында дуслык бәйләнешләрен ныгытуда бәйрәмнәрнең роле зур, чөнки алар аша кешеләр бер-берсенең мәдәниятен, яшәү рәвешен, гореф-гадәте, йолаларын өйрәнә һәм шулар аша бер-берсенә хөрмәт тәрбияли, үз итә, дуслыгын ныгыта. Бүгенге көндә милли бәйрәмнәребез, йола, гореф-гадәтләребез районыбызда яңадан торгызылып, яңартылып, заман төсмерләре биреп үткәрелә башлады. Аларны халык белә, хөрмәт итә икән милләт яши, милләт яшәгәч, тел яши, ягъни тормыш дәвам итә.

## МӘКТӘП МУЗЕЕНА ВИРТУАЛЬ СӘЯХӘТ

***Мухаметова Гөлгенә Халитовна,***
***Имамиева Эльвира Рифатовна,***
*Манзарас урта мәктәбенең туган тел һәм*
*әдәбияты укытучылары ТР КМР*

Рухи, мәдәни мирасны өйрәнү һәм саклау, аны киләчәк буыннарга җиткерү вазифасын иң беренче нәүбәттә музейлар үти. Һәркемгә дә

билгеле булганча, татар халкының тарихи мирасын өйрәнү, аның гореф-гадәтләрен балаларга җиткерүдә мәктәптә музей оештыру мөһим чара булып тора. Музейның даими эшчәнлеген булдыру, минем фикеремчә, укыту – тәрбия эшендә генә түгел, бәлки милли мирасыбызны саклауга һәм өйрәнүгә әйтеп бетергесез өлеш кертә. Туган якны өйрәнү музееның төп максаты – аз яки җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелмәгән материаллар өстендә эшләп, яңалыклар табу, төгәл фактларны күрсәтү.

Шушы максаттан чыгып, безнең Манзарас мәктәбендә дә 2010 нчы елның 25 нче апрелендә укытучылар һәм укучылар тырышлыгы белән «Туган якны өйрәнү» музее ачылды. Музей мәктәпнең бер бүлмәсен алып тора. Барлыгы 500 дән артык экспонат тупланган. Бүгенге көндә дә музей яңа экспонатлар белән баетыла бара.

Экспозицияләрнең эчтәлегенә килгәндә, ул дүрт бүлектән тора.

I бүлек 19 нчы гасыр ахыры 20 нче гасыр башында авылыбызның көнкүреш, яшәү рәвешенә багышланган. II бүлек **«Мәктәп кичә, бүген, иртәгә»** дип атала. Монда Манзарас авылында эләгән мәктәпләрнең тарихы турында сөйли. III **«Сугыш һәм язмышлар»** дип аталучы бүлектә Бөек Ватан сугышы һәм тыл ветераннарының батырлыклары хакында сөйли. Музейда төп урынны IV **«Геройлар безнең янәшәбездә»** дип аталучы бүлек алып тора. Ул Советлар Союзы Герое Сабир Әхтәмовның тормыш юлы турында сөйли. 2009 нчы елдан мәктәбебез аның исемен йөртә. Стеллажда якташыбызның сәгате, кителе, кортигы, ул бүләк иткән китаплар, республикабыз җитәкчеләре тарафыннан бирелгән рәхмәт хатларын, ә стендта героебызның бүләкләре исемлеге, сугыш елларындагы, сугышчан дуслары, яшьләр белән очрашулар вакытында төшкән фоторәсемнәрен күрергә була.

Исән вакытта Сабир ага мәктәбебезгә бик еш кайтты, укучылар белән очрашып үзенең үгет нәсыйхәтләрен бирде. Кайткан саен диярлек музей өчен чиксез кыйммәткә ия булган күчтәнәчләрен калдыра иде.

Шулай ук музейда мәктәбебездә булып киткән танылган шәхесләр турында да экспозиция бар. Алар арасында мәктәпне ачуда катнашкан хәзерге Татарстан президенты Рөстәм Миннеханов, академик Илдар Утямышев, Татарстанның халык артисты Айдар Фәйзрахманов, эзтабар Шаһинур Мостафин, шагыйрә Резеда Валеева, драматург Туфан Миңнуллин, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы председателенең урынбасары Римма Ратниковалар бар.

Сезне дә музеебызда көтеп калабыз.

# ВОСПИТАНИЕ ЛИЧНОСТИ НА ОСНОВЕ НРАВСТВЕННЫХ И ДУХОВНЫХ ЦЕННОСТЕЙ НАЦИОНАЛЬНОЙ КУЛЬТУРЫ

***Нигматуллина Людмила Владимировна,***
***Сабанчеева Наталья Николаевна,***
*учителя МБОУ «Осторма-Юмьинская средняя школа» КМР РТ*

По словам Министра просвещения Сергея Кравцова, одна из важнейших задач системы образования – воспитание гармоничной, социально ответственной личности на основе исторических, культурных традиций, духовно-нравственных ценностей народов России. Задача системы образования сегодня – не только в формировании индивида с широким мировоззренческим кругозором, с развитым интеллектом, с высоким уровнем знаний, но и в развитии духовной личности, от интеллектуального, политического, культурного уровня, от которой во многом будет зависеть будущее общества. От подрастающего поколения будет зависеть то, какое место займет российская культура в мировой цивилизации.

МБОУ «Осторма – Юмьинская средняя школа» Кукморского МР РТ является одной из старейших образовательных организаций, ресурсным центром Этнокультурного образования и воспитания в районе.

Проблема, над которой работает школа: от истории, традиций и культуры удмуртского народа – к интеллектуальному развитию, духовно-нравственному и гражданскому становлению личности ребенка в национальной школе.

Основным содержанием воспитания и социализации личности являются базовые национальные ценности. Эти ценности мы храним в культурных и семейных традициях, передаем от поколения в поколение. Опора на эти ценности помогает человеку противостоять разрушительным влияниям. Общество лишь тогда способно ставить и решать масштабные национальные задачи, когда у него есть общая система нравственных ориентиров. А есть эти ориентиры там, где хранят уважение к родному языку, к самобытной культуре и к самобытным культурным ценностям, к памяти своих предков, к каждой странице нашей отечественной истории.

На всех уровнях общего образования, начиная с дошкольного, намечены основные направления по национальному воспитанию и формированию мотивации к учебной деятельности. Это изучение родного языка и родной культуры, семейных традиций, родного края, знакомство с традициями народов, проживающих в РТ.

В школе ведутся разные кружки, главной задачей которых является приобщение детей к традициям, самобытности, духовности через куль-

туру, сохранение языка, этновоспитание учащихся, изучение истории своего народа.

В сохранении удмуртских традиций и обычаев значимую роль играет краеведческий музей. Периодически он пополняется новыми экспонатами, рассказывающими о культуре и быте жителей села.

Школьная библиотека является центральным местом воспитания, прежде всего нравственной, творческой личности, уважающей историю, ценящей свою культуру. Библиотека раскрывает перед каждым читателем не только разнообразие фонда, но и оказывает информационную поддержку педагогам в проведении урочных и внеурочных мероприятий, в создании тематических проектов.

Коллектив учителей совместно с родителями и учащимися возрождают забытые обычаи и традиции удмуртского народа, используют во внеклассных мероприятиях устное народное творчество: пословицы, сказки, загадки, приметы.

Учителя ведут большую работу по внедрению новых технологий в учебно-воспитательный процесс. Особенно результативным считаем проект «Малый дом ремёсел», основной целью которого является приобщение детей к сохранению и развитию народного декоративно – прикладного искусства и художественных ремёсел. Создана систематическая работа по изучению детьми 4 направлений: ткачество, соломоплетение, роспись по дереву, народная игрушка. Здесь проходят занятия, мастер-классы по изготовлению изделий ручной работы. Таким образом, формируется любовь и уважение к труду, прививается интерес к народным ремеслам и на этой основе – профессиональная ориентация. Через приобретенные навыки – уважительное отношение к носителям родной культуры.

Благодаря государственному проекту «Пушкинская карта» учащиеся с 14 лет посещают различные культурные мероприятия (н-р, концерты, походы в театры, музеи и т.д.) за счет госбюджета. Все это порождает у детей желание приобщиться к культурным ценностям.

Материалы учителей и учащихся постоянно публикуются в различных учебно-методических пособиях, в газетах «Трудовая слава» и «Зечбур!», журнале «Вордскем кыл» и организуются совместные республиканские мероприятия. Учащиеся нашей школы не раз стали победителями различных конкурсов газеты «Зечбур!».

Школа всегда была и есть хранительницей национальных традиций. Именно в школе воспитывается человек, здесь формируются знания, убеждения, мораль. В нашей школе учатся дети разных национальностей, поэтому в школе большое внимание уделяется воспитанию толе-

рантности. Национальное воспитание сочетается с воспитанием у детей чувства национальной гордости, а также уважением к другим народам родной страны. Для воспитания дружелюбного отношения к детям других национальностей в школе организованы различные виды деятельности, использование методов чтения литературы и произведений устного народного творчества, беседы по прочитанным произведениям, проведение национальных праздников (н-р, День национального костюма, День родного языка, День народного единства).

Коллектив школы стремится создать такую инфраструктуру полезной занятости учащихся в урочной и внеурочной деятельности, которая способствовала бы сохранению национальной культуры, формированию гражданской идентичности учащихся.

## ПРОЕКТ: «РОДНОЙ ЯЗЫК – ДУША НАЦИИ ТУГАН ТЕЛ – МИЛЛӘТ КӨЗГЕСЕ»

***Рахматуллина Кадрия Наиловна,***
*заведующий*
***Тазиева Лилия Вагизовна,***
*старший воспитатель*
*МБДОУ «Детский сад №119» Советского района г.Казани РТ*

**Пояснительная записка**

Культурное наследие – это ядро традиционной культуры. Огромный потенциал национальной культуры воспитания детей сосредоточен в народной культуре, языке, так называемом национально-региональном компоненте образования. Великий русский педагог К. Д. Ушинский, проведя сопоставительный анализ, европейских и севера – американской систем образования, пришел к выводу, что, несмотря на сходство преподаваемых предметов и используемых методик, педагогические системы обладают четкой национальной спецификой, которая отражает «душу народа», его менталитет. Любовь к Отечеству, к культуре и обычаям своего народа не разъединяет, а наоборот, объединяет людей. Насыщая жизнь детей в детском саду фольклором, народными играми, праздниками, знакомя детей с традициями мы воспитываем детей в духе терпимости, уважения и интереса к культуре народов, живущих в Татарстане.

Проект направлен на сохранение и развитие культуры, традиций, языков народов, сохранение гражданской и татарстанской идентичности, воспитание у подрастающего поколения интереса к изучению родного

языка, его истории и современности, народному искусству, на стремление к самовыражению посредством творческой деятельности.

**Цель проекта:**

Формирование основ нравственного сознания и воспитание патриотических чувств дошкольников путем приобщения их к культуре народов Поволжья.

**Задачи:**

✓ Обобщить и систематизировать современные методики и технологии, направленные на изучение родного языка, культурных традиций народов, проживающих в нашей республике;

✓ Обогащение предметно-развивающей среды с целью обеспечения максимальной реализации образовательного потенциала пространства ДОУ;

✓ Разработать комплекс мероприятий, направленных на развитие родного языка и культурных традиций народов родного края;

✓ Создать модель сохранения и развития языков, традиций, культур народов, проживающих в нашей республике, способствующей повышению качества образовательного процесса;

✓ Создание условий для усвоения духовно-нравственных ценностей, принятых в обществе, включая этнокультурные и традиционные ценности.

**Вид проекта:** познавательно-творческий.

**Срок реализации:** долгосрочный.

Обоснование значимости проекта: приобщение детей к национальной культуре – одна из самых актуальных проблем дошкольного образования на современном этапе в силу коренных изменений, происходящих в нашем обществе. Регион Поволжья можно считать уникальной лабораторией поиска путей развития личности через взаимодействие культур. Исходя из многолетнего опыта дошкольного образования, можно утверждать, что дошкольникам доступны патриотические чувства, поэтому начинать работу в этом направлении необходимо уже в детском саду.

По мнению А.П. Усовой, маленьким детям еще не доступно сознательное усвоение понятия Родины, патриотическое воспитание в этом возрасте состоит в том, чтобы подготовить почву для него. Такой благоприятной почвой и является народное творчество во всем его многообразии. И не надо придумывать ничего нового, это уже есть в каждом из нас.

В настоящее время накоплен достаточно большой опыт по патриотическому воспитанию дошкольников, разработаны научно – обоснованные методики по данной проблеме, но недостаток методических пособий по национально – региональному компоненту общеобразовательной про-

граммы дошкольного образования определил выбор темы нашего проекта. Национальная культура может быть сохранена и продолжена в веках только в случае приобщения и формирования интереса к ней у подрастающего поколения с ранних лет. Сохраняя традиции прошлого, мы сохраняем себя, свой народ, культуру, традиции семьи.

Актуальность проекта состоит ещё и в том, что в дошкольных учреждениях нет системы по глубокому ознакомлению дошкольников с народно-прикладным искусством. Этот проект даст детям знания о наиболее известных народных промыслах, научит выполнять узоры декоративных росписей и гордиться культурным наследием своего народа.

**Новизна проекта:** состоит в использовании новых, нетрадиционных форм проведения занятий по направлениям деятельности:

– Историческое моделирование изделий народов Поволжья.

В итоге: выставка – сравнение изделий старины и современности;

– Игры народов Поволжья

– Самостоятельный поиск народных игр воспитанниками и проведение их на занятиях и развлечениях.

Итоговый фольклорный праздник с обрядами и традициями народов Поволжья. Представление своих национальных изделий в обрядах через театрализацию.

Целевые группы проекта: воспитанники МБДОУ, родители, воспитатели, музыкальный руководитель, воспитатель по обучению родному языку;

Социальные партнеры*:* Национальный музей Республики Татарстан, литературный музей Г. Тукая, Союз писателей Татарстана, Дом Дружбы народов Татарстана, мастерская текстильных изделий в татарском стиле «Казан сөлгесе», Государственный ансамбль фольклорной музыки РТ.

Планируемые результаты проекта:

✦ статьи в изданиях районного и республиканского уровня о ходе реализации данного проекта;

✦ издание и публикация методического материала по проблеме, организация сайта в Интернете;

✦ осуществление обмена опытом в рамках сотрудничества с другими ДОУ Советского района, города Казани, и Республики Татарстан;

✦ отчеты с приложениями по завершению каждого этапа проекта;

✦ повышение степени активности родителей и их участия в жизни ДОУ;

**Планируемые результаты у детей:**

✦ повышение уровня нравственно-патриотических чувств воспитанников, знаний о народах Поволжья, культуры поведения дошкольников;

✦ раскрытие индивидуальности ребенка; возрастание духовно-эмоционального контакта «ребенок – взрослый – ребенок»;

✦ позитивное отношение к миру;

✦ обогащение опыта детей по духовно-нравственному, художественно-эстетическому воспитанию посредством приобщения к ценностям народной культуры, проживающих в Республике Татарстан;

✦ принятие детьми самостоятельных решений в разных видах деятельности, умение творчески применять имеющуюся информацию по различным элементам народной культуры, успешность каждого ребенка.

**Формы и методы работы:**

✦ непосредственно образовательная деятельность

✦ совместная деятельность

✦ самостоятельная деятельность

✦ взаимодействие с родителями

✦ взаимодействие с социальными партнерами (экскурсии, совместные мероприятия)

В своей работе мы так же используем метод интеллект-картирования. Этот метод эффективный, в то же время не сложный в использовании. Благодаря интеллект-картам дети лучше запоминают изученный материал. Для примера возьмем тему народные праздники. Первым делом мы проговариваем, вспоминаем каждую мелочь по этой теме: традиции нашего народа, главные атрибуты праздника, какие праздники считаются народными и т.д. Затем в середине ватмана рисуем главную картинку, которая ассоциируется с темой (майдан, национальная борьба и т.д.). Затем рисуем от главной картинки (слева-направо) стрелки разных цветов. Под каждой стрелкой мы делаем рисунок (разбиваем главную тему на подтемы). А уже каждую подтему раскрываем рисуя дальше стрелочки того же цвета, с помощью рисунков, которые выполняют дети. Таким образом интеллект – карту дети создают самостоятельно, при этом запоминая и закрепляя данную тему. За основу можно взять любую другую тему: весна, осень, насекомые, животные, путешествие и т.д.

В проекте предусмотрены и формы работы с родителями. Это и традиционные родительские собрания, беседы, консультации, семинары-практикумы, встречи с интересными людьми, экскурсии, мастер-классы.

Подготовлено:

– Игротека дидактических игр и занятий по ознакомлению с культурными традициями народов родного края;

– Картотека интерактивного веб-квеста по изучению родных языков, традиционных игр для детей дошкольного возраста;

– Картотека игр народов Поволжья;

– Папки-альбомы: «Народные промыслы», «Халкыбызның күңел бизәкләре»;

– Буклеты;

– Цикл бесед для детей о татарском быте, семейных традициях; «История бабушкина сундука», «Игрушки наших бабушек и мам», «Татарстан – наша Родина», «Добрые соседи -лучшие друзья», «Жить интересно потому, что мы разные», «Что такое орнамент?», «Лечебные свойства шерсти»;

– Консультации для родителей: «Предметы быта дедушек и бабушек», «Роль музея в познавательном развитии дошкольников»; «Зачем нужны музеи?», «Польза рукоделия в развитии детей дошкольного возраста», «К гармонии через рукоделие», «Мастерим и общаемся вместе с ребенком», «Народные традиции и их роль в семейном воспитании»;

– Лэпбуки на темы:«Лучезарная Казань»,«Мой край родной»,«Милли татар киемнәре»,«Татар халык ашлары»;

– Подпроекты по народным промыслам: «Хохлома», «Гжель», «Дымковские игрушки», «Эх, валенки!», «Тамбурная вышивка», «Актюбинские игрушки»;

– Изделия, украшенные хохломской, гжельской росписью для выставки – разделочные доски, мисочки, ковши, ложки, вазы, тарелки.

– Пополняется музей детского сада «Милли мирас»

Обобщая опыт по приобщению детей к татарскому культурному наследию, можно сказать, что таким образом мы знакомим родителей и педагогов с лучшими отечественными традициями семейного воспитания, создаем атмосферу добра, доверия, взаимопонимания между детьми и взрослыми, которая способствует раскрытию познавательных, творческих и личностных возможностей ребенка.

Только в сотрудничестве с семьей можно воспитать настоящего человека и патриота. Надеемся, что опыт педагогов нашего детского сада поможет коллегам в работе по приобщению детей к культуре народов Поволжья средствами музыкального фольклора, декоративно-прикладного искусства, поможет привить детям интерес к татарским напевам, играм, танцам.

**Литература:**

1. «Татар дөньясы – Татарский мир» Издательство Заман – Казань, 2020
2. Харисов Л. А. «Ватаным Татарстан – Родина моя» – Казань, 2005
3. Зарипова З. М. «Белем бирү һәм тәрбия процессында милли төбәк компоненты» – Яр Чаллы, 2000
4. Борһанова Р. А. «Татар халкының мәдәнияте белән таныштыру» – Казан, 1994

5. Закирова К. В. «Әхлак нигезе– матур гадәт» – Казан, 2004
6. Р. Ф. Ягъфәрова «Балалар фольклоры» Казан, Мәгариф 2000
7. Нурзия Сергеева «Веков связующая нить. Татарское декоративное и изобразительное искусство для детского творчества» – Казань, 2004
8. Ф. Ф. Харисов «Национальная культура и образование» Москва, 2000
9. Зарипова З. М., Исаева Х. Б., Кидрячева Р. Г. «Балалар бакчасында рус балаларына татар теле өйрәтү» 2013. Казан. «Татмедиа»

# «ХАЛЫК БЕРДӘМЛЕГЕ – ҖИҢЕЛМӘС КӨЧ» ДИГӘН ТЕМАГА МӘКТӘПКӘ ХӘЗЕРЛЕК ТӨРКЕМЕ БАЛАЛАРЫ ӨЧЕН БӘЙРӘМ КОНСПЕКТЫ

***Сәйфетдинова Дамира Гаязетдин кызы,***
*тәрбияче*
***Шәймәрдәнова Гөлия Камил кызы,***
*физик тәрбия буенча инструктор*
*«Кукмара шәһәре унынчы номерлы «Ромашка» һәрьяктан үстерешле балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*

**Максат.** Балаларда Идел буе халыкларының фольклоры, җырлы-биюле, хәрәкәтле уеннары аша туган илгә, туган телгә, төрле милләт халыкларының гореф-гадәтләренә мәхәббәт, ярату, кызыксыну тәрбияләү.

**Бурычлар.**

– Балаларның үзара һәм өлкәннәр арасында аралашу күнекмәләрен үстерү.

– Хәрәкәтләнү күнекмәләрен: көч, җитезлек, тизлек, сыгылмалылык, чыдамлык, хәрәкәтләрне координацияләүне үстерү.

– Балаларда дуслык, башкаларның уңышларына сөенеп яши белүне тәрбияләү.

**Җиһазлау**. Проектор, презентация, яулыклар, солтанчиклар, флаглар, милли костюмнар, уеннарга атрибутлар.

**Бәйрәм барышы**

Балалар татар, рус, удмурт милли киемнәреннән «Дуслык гимны» астында залга керәләр (Д. Тухманов музыкасы, Р. Рождественский сүзләре)

**Алып баручы.** Кадерле балалар, хөрмәтле кунаклар!

*Йөри безнең бакчага*
*Бик күп төрле балалар,*
*Төрле – төрле телләрдә*
*Сөйләшә белә алар.*

Безнең республикабыз күп милләтле. Анда татар, рус, удмурт, чуваш, мари халыклары яши. Балалар, ә безнең бакчага нинди милләт балалары йөри?

**Балалар җавабы:** татар, рус, удмурт.

**Алып баручы.** Бик дөрес. Сез узара дус, тату аралашасыз. Туган телгә мәхәббәт, ярату гаиләдән, балалар бакчасыннан башлана.

Татар, рус, удмурт балалары үз туган телләрендә шигырьләр өйрәнделәр.

1. Татар теле – минем туган телем
Сөйләшүе рәхәт ул телдә.
Шул тел белән көйлим...
Шул тел белән сөйлим
Милләттәшем булган һәркемгә.

2. Родной язык!
Он с детства мне знаком,
На нём впервые я сказала «мама»,
На нём клялась я в верности упрямо,
И каждый вздох понятен мне на нём.

3. Анай кыл-улонэ нырысь вамыш,
Сотэк уд лэсьты мукетсэ вамыш.
Анай музэн,
Анай кылыд юрттоз,
Улон сюрес кузя йыгмыт валтоз.

4. Дружба – это доброта,
Труд и уважение.
И для нас она не служба,
А одно спасенье.

5. Доверяй своим друзьям!
Будь, терпим и вежлив!
Не кричи по пустякам!
Не кати ком снежный!

6. Дус яшәргә кирәк җир йөзендә,
Дуслар кирәк һәрбер кешегә.
Дуслык булса яшәү дә куңелле,
Уңай була һәрбер эшең дә.

**Физик тәрбия буенча инструктор.** Балалар без бүген сезнең белән җырлы-биюле, төрле халык уеннарын уйнарбыз.

**Бала.** Мы в любимом Татарстане дружно, весело живём.
По-татарски, по-удмуртски и по-русски мы танцуем и поём.
Веселиться вместе с нами всех друзей к себе зовём.

### Флешмоб «Мин яратам сине Татарстан»

**Алып баручы.** Һәр милләтнең үзенә генә хас булган җырлы-биюле, хәрәкәтле уеннары бар. Бүген без сезнең белән Идел буе халыкларының җырлы-биюле, хәрәкәтле уеннарын уйнарбыз. Ә хәзер бәйрәмебезне татар халкының җырлы – биюле уеннары белән дәвам итик. Балалар белән бергәләп татар халкының «Түбәтәй», «Йөзек салыш»,«Утыр, утыр Мәликә» уеннарын уйнау.

Ә хәзер без сезнең белән рус халык хәрәкәтчән уеннарын уйнарбыз. «Горелки с платочком», **«Гуси – лебеди» уеннарын уйнау.**

**Физик тәрбия буенча инструктор.** Молодцы ребята, вы играли дружно. А теперь, я проверю, как вы знаете русские народные пословицы. Ведь пословица – это душа и ум русского народа.

1. «Лес рубят… *(щепки летят)*»
2. «Волков бояться… *(в лес не ходить)*»
3. «Шила в мешке… *(не утаишь)*»
4. «Сделал дело … *(гуляй смело)*»
5. «Без труда *(не выловишь и рыбку из пруда)*»
6. «Делу время *(потехе час)*»

**Кулъяулыклар белән рус халык биюе «Россияночка»**

Бәйрәмебезне удмурт халык уеннары белән дәвам итәбез «Сукыр така» («Слепой баран»), «Круген бергаса» («Хороводная игра») уеннарын уйнау.

**Удмурт халык биюе «Ялыке»**

**Интерактив уен «Милли киемнәрне дөрес итеп әйт һәм курчакны киендер»**

Балалар интерактив такта янына чыгып, экраннан татар, рус, удмурт, мари, чуваш милли киемнәрен дөрес итеп аерырга һәм курчакны милли киемнәр белән киендерергә тиеш.

**Физик тәрбия буенча инструктор.** Балалар мин сезгә Идел буе халыкларының табышмакларын тәкъдим итәм. Сездән тапкырлык, игътибарлылык сорала.

Татар. Утта янмый, суда батмый. *(Боз)*

«Ак ашьяулык таптым, җир өстенә яптым» *(Кар)*

Башкорт. На четырех парней одна шапка надета? *(стол)*

Чуваш. Языка нет, а рассказывает? *(книга)*

Мари. Кнутом не гонят. Овсом не кормят. Когда пашет – семь пудов тянет? *(трактор)*

Рус. Два брюшка, четыре ушка? *(подушка)*

Никогда не меняются: и ночь работают, и день работают? *(часы)*

**Алып баручы.** Безнең бәйрәмебез ахырына якынлашты. Сез төрле телләрдә уеннар уйнадыгыз, биедегез, җырладыгыз, матур итеп шигырьләр сөйләдегез. Туган телегезне онытмагыз, хәр милләт халыкларының гореф-гадәтләрен хөрмәт итегез.

*Телебезне күңел гөле итеп*
*Саф көенчә саклыйк гомергә.*
*Рухи дөньяң булсын халкың моңы*
*Туган телең йөрсен синең белән бергә.*

**Бергәләп Г.Тукайның «Туган тел» җырын башкару**

**Алып баручы.** Кадерле балалар, хөрмәтле кунаклар, менә сезнең белән саубуллашыр чак та җитте. Сау булыгыз! Бүгенге бәйрәм сезнең күңелләргә дәрт өстәсен.

## РОССИЯ ХАЛКЫНЫҢ МӘДӘНИ МИРАСЫ

***Степанова Райхана Сахаб кызы***
*балаларны татар теленә өйрәтүче тәрбияче*
*«Кукмара шәһәре җиденче номерлы «Кыңгырау» һәрьяктан үстерешле балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениясе*

Бүгенге көндә, ФББП (федераль белем бирү программасы) шартларында, кешенең сыйфатлары гасырлар дәвамында формалашуы һәм буыннан буынга үтәлергә тиешле васыять итеп тапшырылуы, сүнмәс учагы булып мәктәпкәчә тәрбия бирү оешмасы тора. «Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге булмас» – ди татар халык мәкале. Татар халкын милләт буларак саклап калу, үстерү, үткәннәр турында түкми-чәчми балаларыбызга тапшыру ─ бу инде без тәрбиячеләрнең төп вазифасы. Күңелендә аз гына милли хисе булган кеше дә моңа битараф кала алмый торгандыр. Ана теле – сабыйларга аң-белем һәм тәрбия бирү өчен иң шифалы чишмә. Чишмәнең башы исә туган яктан башлана.

**Тикшеренү максаты**: мәктәпкәчә яшьтәге балаларның туган җиренә, иптәшләренә, туганнарына, төрле милләт халкына булган хисләренең ролен теоретик нигезләрдә һәм эксперименталь рәвештә тикшереп проеклаштыру методын сайладым мин.

**Тикшеренү объекты:** мәктәпкәчә яшьтәге балаларда туган якка мөнәсәбәт, патриотизм, милли тәрбиянең ролен ачыклау.

**Тикшеренү гипотезасы:** милли патриотизм тәрбияләү билгеле бер шартларны тормышка ашырганда гына уңышлы булачак: тәрбия процессы мәктәпкәчә яшьтәге балаларның төрле милләт халкына мәхәббәт тәрбияләү төшенчәсе эчтәлеген исәпкә алып тормышка ашыру; әби-бабаларыбызның үткән тормышы, йола, гореф-гадәтләре, туган җиребезнең күренекле кешеләрен өйрәнүне этаплы алып бару.

**Максаттан һәм гипотезадан чыгып, түбәндәге бурычларны куйдым:** мәктәпкәчә яшьтәге балаларның гуманлы хисләр тәрбияләү үзенчәлекләрен билгеләү; балаларның милли патриотизм, милли мәдәни-тарихи белемнәре күрсәткечләрен һәм дәрәҗәләрен ачыклау.

Куелган бурычларны чишү өчен кулланылган **тикшеренү методлары**: балалар эшчәнлеген күзәтү, тәрбиячеләр, әти-әниләр , балалар белән эш алып бару, кызыксындыручан оешмалар белән эш. Тикшеренү эшенең **фәнни яңалыгы** түбәндәгечә: мәктәпкәчә чорда туган телгә, туган якка мәхәббәт тәрбияләү, балаларның төрле милләт халкына булган мөнәсәбәтләрен билгеләү, милли җанлы шәхес сыйфаты буларак үз милләтенә һәм башка милләт халкына булган карашларын формалаштыруны теоретик нигезләү һәм эксперименталь тикшерүне проект методы аша өйрәнү.

**Балалар бакчасында милли тәрбияне проектлаштыруда тәрбияче роле:**

Туган җиребез тарихы турында мәгълүмат туплау; иҗади төркем белән куелган максатны тормышка ашыру буенча системалы эш алып бару; ата-аналар белән тиешле дәрәҗәдә эшләү; күргәзмәләр, конкурслар оештыру, экскурсияләргә йөрү; төркемнәрдә милли (татар, рус, марый, башкорт, удмурт, чуваш, керәшен) үзәкләр булдыру.

**Балалар бакчасында туган җирнең милли мәдәниятын өйрәнүдә оештырылган эшләр:**

Педагогик киңәшмәләр,семинар-практикумнар, сәнгатьле укулар, консультацияләрдә катнашу; танылган якташлар белән очрашулар; туган якны өйрәнү буенча перспектив планнар төзү, методик киңәшләр эшкәртмәсе булдыру, ачык шөгыльләр, методик берләшмәләр, бәйге-конкурслар оештыру; үз белемең үстерү эшен камилләштерү, югары дәрәҗәдәге тәҗрибәләр белән уртаклашу; лепбуклар, презентация төзү, милли дидактик уеннар ясау.

**Балалар бакчасында милли тәрбия өйрәнү системасын проектлаштыруда балалар белән оештырыла торган эшләр:**

Шөгыльләр, әңгәмәләр, максатлы сәяхәтләр, тематик кичәләр; музыкаль әдәби кичәләр, викториналар, конкурслар,күргәзмәләр,әкиятләр сәхнәләштерү **Балалар бакчасында туган җирне өйрәнү системасын проектлаштыруда әти-әниләр белән оештырыла торган эшләр:**

Төрле алымнар кулланып төркем белән һәм гомуми җыелышлар үткәрү, төрле ситуатив мәсьәләләр чишү, мастер класслар, мавыктыргыч ярышлар, бәйгеләр, күңел ачулар, тематик кичәләр, музыкаль әдәби кичәләр, викториналар үткәрү,гаилә шәҗәрәсе, йолаларын, бишек җырларын өйрәнү.

**Балалар бакчасында милли тәрбия өйрәнү системасын проектлаштыруда җәмәгатьчелек белән эш:**

Мәктәп, туган як музее, китапханә, Кукмара телевидениясе, Хезмәт даны газетасы, Ак калфак белән бердәм эшчәнлек;

**Балалар бакчасында милли тәрбия өйрәнү системасын проектлаштыруда эшне анализлау, милли тәрбиянең ролен ачыклау:**

Милли рухи байлык аерым халыкның гына түгел, ул – гомум кешелек кыйммәтләренең нигезе. Димәк, балаларны кечкенәдән үк үз халкының, үз туган җиренең үзенчәлекләре белән таныштыру гомум кешелек кыйммәтләре белән таныштыруның башлангычы булып тора. Безнең бурыч – үткән буыннар туплаган рухи байлыкны саклап, баетып, аның кешелек тарафыннан иң кыйммәтле дип табылган үрнәкләрен балаларга җиткерү.

Безнең милли-региональ «Туган якны өйрәнәбез» тәрбия программасының **фәнни яңалыгы** түбәндәгечә: милли җанлы шәхес сыйфаты буларак үз милләтенә һәм башка милләт халкына булган карашларын формалаштыруны үз туган җирен хөрмәт итүче патриот, мәдәни белемле шәхес тәрбияләүдән башлау. «Берәү башка телне өйрәнмәкче булса, иң элек үз теленнең грамматикасын яхшы белсен». . дигән халкыбызның бөек шагыйре Г Тукай. Балаларны ана телендә яхшы итеп сөйләргә өйрәтү,тел системасының фонетик, лексик, грамматик төзелешен формалаштыру, бәйләнешле сөйләм үстерү максатыннын, «Туган телдә сөйләшәбез» укыту методик комплектын кулланам. УМК балаларга телебезнең матурлыгын, байлыгын аңларга, үзләрендә күркәм сыйфатлар тәрбияләргә,туган җиребезгә, телебезгә мәхәббәт, әти-әниләргә, өлкәннәргә карата хөрмәт-итәгать тәрбияләргә, тыйнаклык, шәфкатьлелек кебек сыйфатлар булдырырга ярдәм итә.

Балаларыбызны милли җанлы итеп тәрбияләү туган телебезнең башында торган бөек шәхесләребез турында мәгълүмат бирүдән башлана, шагыйрьләребез, язучылар шигырьләре белән таныштырудан башлана. Болар сойләм үстерү шөгыльләре вакытында, режим моментларында, «Тел күрке – сүз» проекты кысаларында башкарыла. Татар халкының милли мәгариф системасы электән килгән «Яхшы, мул тормышта яшәү өчен, кеше, иң беренче чиратта, белемле һәм тәрбияле булырга тиеш » дигән акыллы фикергә таянып эш итәм. Бу фикер бөтен мәгърифәтчеләр өйрәтмәләренә барып тоташа, белем бирү белән тәрбия бирүне бәйләп алып бару принцибын алга чыгара. Күп милли мәдәниятле Россия шартларында башка милләтләр мирасы белән таныш булу зарур. Курше республикалар турында да мәгълүматлар туплап лепбуклар ясадым, шөгыльләр вакытында, режим моментларында да аларны еш кулланырга тырышам.

Үземнең «Кыңгырау» балалар бакчасында мирас булып буыннан буынга күчеп килә торган байлыкка зур игътибар бирергә тырышам. Йола, гореф-гадәт һәм бәйрәмнәребез безнең бик матур һәм истәлекле үтә.

Һәр милләтнең үзенә генә хас яшәү, көнкүреш итү, үз-үзен тоту кагыйдәләре формалаша. Татар халкында «Аулак ой», «Кичке уеннар» , «Солдатка озату», «Каз өмәсе» йолалары аша аларның күбесе буыннан буынга тапшырылган, заман таләпләреннән чыгып камилләштерелгән. Вакыт узу белән, милли үзенчәлекләрнең кайберләре юкка чыга, яңалары барлыкка килә.

Бәйрәмнәр, гореф-гадәтләрне балаларга өйрәтүдә төп вазифаны билгеле гаилә башкара. Кош, оясында нәрсә күрсә, очканда шуны эшли, ди халык. Гаилә милли традицияләргә уңай караштa булса, татар милләтенең үзенчәлекләрен исәпкә алып яшәсә, балалар дә улай яшәргә күнегәләр.

Халык бәйрәмнәре – шул халыкны милләт итеп берләштерә торган чараларның берсе. Һәр милләтнең үзенә генә хас бәйрәмнәре була. Әгәр дә халык бәйрәмнәре югала, юкка чыга икән, бу инде аның рухи байлыклары саега баруын чагылдыра.Шуңа күрә без дә үзебезнең «Кыңгырау» балалар бакчасында әти-әниләр белән, әби-бабайлар катнашында милли бәйрәмнәрне еш үткәрәбез: «Сабантуй», «Нәүрүз», «Сөмбелә», «Карга боткасы», төрле милләт халкының уеннары.

Әти-әниләр үрнәгендә һәм йогынтысында милли киемнәрнең кайберләре әкренләп кире тормышка кайтарыла башлады. Калфаклы, ак яулыклары кызлар, чигүле түбәтәйләрне егетләр бәйрәмнәрдә генә түгел, башка вакытларда да гадәти күренешкә әверелеп бара. Балаларыбызны «Татар егете һәм татар кызы» конкурсларында катнаштырып милли киемнәребезнең матур үрнәкләрен курсәтәбез. Әти-әниләрнең милли традицияләребезне саклаудагы роле балаларны төрле эшчәнлектән тыш чараларга тартуда да күренә.

Шәхсән үзем «Милли киемнәр» конкурсында катнашып, башкорт, мордва, рус, чуаш, керәшен, татар киемнәрен булдырдым. «Туган җирем – Татарстан» информация почмагын бай, зәвыклы материаллар белән тулыландырдым, милли лэпбуклар эшләдем. Бу мисаллар барысы да әгәр теләк булса, күңел бирелсә, милли гореф-гадәтләребезне саклап кала алуыбызны күрсәтер дип ышанасым килә минем.

Халкыбызның рухи байлыгын, тарихи-мәдәни мирасын түкмичәчми яшь буынга җиткерү өчен, музейлардан башка күз алдына да китереп булмый. Татар халкының мәдәнияте белән даими таныштырып тору өчен безнең үзебезнең балалар бакчасында дә «Туган як» минимузее булдырдык.

Без – бала күңеле белән эш итүче тәрбиячеләр бу мәсьәләгә аерууча игътибар күрсәтергә тиешле. Чөнки нәкъ менә сабый чакта, дөньяга караш формалашканда баланың күңеленә үз милләтенә, диненә, гореф-гадәтләргә мәхәббәт орлыклары чәчеп калдыру кирәк.

Кыскасы, милләтебез тарихы һәм мәдәнияты – балалар өчен бик кызыклы өлкә. Кызыксынулары көчле булганга, өйрәтү, аңлату да җиңелгә килә. Шул рәвешле безгә, әлеге кызыксынудан файдаланып, сабыйларда милли узаң, горурлык тәрбияләү мөмкинлеге бирелә.

Без мәктәпкәчә белем бирү хәзмәткәрләре ата-аналар белән берлектә кешелекле, милли аңлы шәхес, сәламәт рухлы патриот тәрбияли алсак, милли тәрбиянең роле шунда күренәчәк.

## РАЗВИТИЕ ЛИЧНОСТИ РЕБЕНКА ЧЕРЕЗ ОЗНАКОМЛЕНИЕ С ФОЛЬКЛОРОМ НАРОДОВ ПОВОЛЖЬЯ

**Фатихова Рузия Камиловна**,
*воспитатель, МБДОУ «Детский сад д. Аш-Бузи» КМР РТ*

*«Дружелюбие, уважение к людям разных национальностей не передаются по наследству, в каждом поколении их надо воспитывать вновь и вновь, и чем раньше начинается формирование этих качеств, тем большую устойчивость они приобретут»*

***Э.К. Суслова***

Рәсәй Президенты Владимир Владимирович Путин 2023 елны «Укытучы һәм остаз елы» дип игълан итте. Бу карар укытучыларның югары статусын тану һәм аларның башкарган эшенең мөһимлеге турында сөйли. Президент биргән күп йөкләмәләр укытучы һөнәренең абруен күтәрүгә, аларга социаль ярдәм күрсәтүгә, һөнәри үсешкә карашны үзгәртүгә юнәлтелә. Укытучы һәм остаз елының бурычы – бу һөнәргә игътибар юнәлтү, укытучыларыбызга тиешле хөрмәт күрсәтү генә түгел, ә яшьләрнең педагогикага кызыксынуын арттыру, югары уку йортын тәмамлаганнан соң, мәктәпкә эшкә киләчәк иҗади, сәләтле, актив абитуриентларны педагогик вузларга җәлеп итү.

Мөгаллим, остаз, укытучы... Бу өч сүздә күпме мәгънә, күпме сер. Алар җилкәсенә гаять катлаулы эш – тәрбия һәм белем бирү эше йөкләнгән. Бүгенге чынбарлык эти – әниләрдән, тәрбиячеләрдән һәм укытучылардан зирәклек күрсәтүне, тәрбия эшенә яңача карауны, яңа алымнар куллануны таләп итә.

«Укытучы – ул балалар күңеленә нур сибүче җылы кояш», -дип яза К. Ушинский. Әйе, бу чыннан да шулай. Чөнки бала вакыттан без бу сүзне ишетеп үсәбез. Минем күңелемдә укытучы гади кеше генә түгел, ә бәлки могҗиза тудыручы да булып саклана. Чөнки иң беренче дөньяны танырга, серле хәрефләр-дән сүзләр төзергә, тыңлаусыз ручканы кулга тотып дәфтәр юлларына сызыклар, хәрефләр язарга бары укытучы гына өйрәтә. Укытучы – ул безнең туган ягыбыз, безне чолгап алган тирә – як: табигать, урман, су, һава, чишмәләр һ. б.

Минемчә, бүгенге замана укытучысының төп максаты – үз белемнәрен башкаларга өләшү, шул белемнәр ярдәмендә ирекле кеше тәрбияләү. Бүгенге укытучы вакыт белән бергә атлый, ул һич тә заманадан артта калырга тиеш түгел. Эрудицияле, энергияле һәм кыю укытучылар гына бу таләпне үти ала.

Балачакның иң көтеп алынган һәм зарыктырган мизгеле – мәктәпкә укырга керү. Һәркемнең тизрәк үсәсе, зур буласы һәм укыйсы, язарга өйрәнәсе килә. Мәктәп, белем, китаплар, хәрефләр, дәрес, кыңгырау тавышы, бик серле булып үзенә дәшеп тора. Ә укытучы дигән илаһи зат бөтен нәрсәне дә белә, өйрәтә, барлык сорауларга да җавап бирә ала.

Мин дә, 1983 елның 1 сентябрь иртәсендә, Кукмара районы Зур Сәрдек мәктәбенең 1нче сыйныфына укырга кердем. Мине анда ягымлы, ачык

йөзле укытучым – Ибатуллина Лена Гыйлмулла кызы каршы алды һәм классска алып керде. Бик якты иде ул. Тәрәзә төбе тулы гөлләр. Каршыда такта. Анда укытучы апа «Әти», «Әни», «Мәктәп» дигән сүзләр язды. Без – укучылар өчен күңелле көннәр башланды. Укырга, язарга өйрәндек. Ә аннары бергәләп « Әлифба бәйрәме» үткәрдек. Без «А», «Б»... хәрефләре булдык. Нәкъ әлифбадагыча уйнадык, биедек, җырладык, табышмаклар чиштек. Без 5 кыз һәм 8 малай бердәм гаилә булып яшәдек, кызыклы экскурсияләр, походлар безнең тормышыбызны тагын да ямьләндерде, балачакның бәхетле мизгелләренә шатлык өстәде. Укытучым һәр дәресен «Укучыларым, мин сезне күрүемә бик шат һәм сезнең белән аралашуны көтеп алам», – дигән сүзләр белән башлады. Лена Гыйлмулла кызы үз артыннан укучыларын да ияртте, юнәлеш бирде һәм без үзебез дә сизмәстән эзләндек, уйландык, иҗат иттек, ачышлар ясадык. Еллар үтте, мин дә үстем. Иҗекләп укыган чаклар артта калды. Калын– калын китапларны 2-3 көндә укып чыгам, матур хатлар, иншалар да язам.

Беренче укытучым – Лена Гыйлмулла кызы, минем киңәшчем, иптәшем дә булды. Башлангыч мәктәп елларының кыңгырау чыңы минем җанга һәрчак үзенчә бер ләззәт биреп торучы мизгел булып истә калды. Алай гына да түгел, үзе белән ул балачакның хатирәләрен дә яңарта, уйландыра, сагышландыра. Беренче карашка башлангыч мәктәптә уку еллары сизелми дә үтте кебек. Әмма тормыш сукмагының зур һәм җаваплы өлешен алып тора икән ул чор.

Башлангыч мәктәп, беренче укытучы– ул белем учагы гына түгел, балачак йорты да. Эх, кабаттан ак алъяпкычлар белән кулмәкләр киеп, ак бантиклар тагып, чәчәк гөлләмәләре тотып, беренче сыйныфка укырга барырга иде. Юк, бу хыял гына. Ләкин мин ел саен нәниләрнең сөенеп һәм горурланып, зур өметләр белән укырга, белем йортына килүен күрәм. Чөнки мин бүгенге көндә үзем дә укытучы... Әйе, 19 ел дәверендә йөзләгән, меңләгән укучыларымның хөрмәтен тоеп яшәү– миңа укытучы һөнәренә тугъры калып, үз хезмәтемне яратып, вакыт белән исәпләшмичә башкарырга көч бирә.

Бүгенге укытучы хезмәте бик авыр. Ә укытучы эшендә иң түземле һәм иң сабыр, гадел, заман таләбенә җавап бирүчеләр генә эшли ала минемчә. 2023 ел – Рәсәйдә остаз, педагог елы уңаеннан, мин барлык укытучыларыма гаилә бәхете, күңел тынычлыгы, сәламәтлек, иман байлыгы, сабырлык, озын гомер телим.

# СЕКЦИЯ III

# СОХРАНЕНИЕ И РАЗВИТИЕ ПЕДАГОГИЧЕСКИХ ТРАДИЦИЙ УЧИТЕЛЕЙ-ПРОСВЕТИТЕЛЕЙ РОДНОГО КРАЯ

## ВЫДАЮЩИЙСЯ УЧИТЕЛЬ-ПРОСВЕТИТЕЛЬ НИКОЛАЙ ИЛЬМИНСКИЙ

***Гарифуллина Чулпан Рамиловна,*** *учитель истории*
*МБОУ «Средняя общеобразовательная*
*школа им. С. А. Ахтямова с. Манзарас» КМР РТ*

В стенах учительской семинарии Ильминскому удалось создать просветительскую систему, распространившуюся в Поволжье. «Мои снаряды – инородческие книги, школы, учителя – инородцы, богослужения на инородческих языках» так одним предложением можно определить русло деятельности Николая Ильминского.

Ильминский в 1870-е годы столкнулся со сложностями при наборе учеников. Он был вынужден отправлять учителей в командировки в различные глухие селения для привлечения воспитанников. Однако к началу XX века от желающих поступить в семинарию не было отбоя.

Семинария под руководством Ильминского была известна своей переводческой работой и работой по составлению учебных и миссионерских книг для инородческих племен. Эти труды экспонировались на Парижской всемирной выставке. Всего 212 изданий на русском и различных инородческих языках. Издания эти были выставлены от имени православного миссионерского общества, делопроизводство и издательская деятельность которого находилось под руководством Николая Ильминского. Столь почтенная деятельность сделала ее известной среди отдаленнейших инородческих племен, для которых она составляла переводы и готовила учителей и миссионеров-священников.

**Список использованной литературы:**

1. Ильминский Н. И. «О системе просвещения инородцев и о Казанской центральной крещёно-татарской школе». Литотипография И. Н. Харитонова.
2. Витевский В. И. Н. И. Ильминский, директор Казанской учительской семинарии. Казань.
3. Рождествин А. С. Николай Иванович Ильминский и его система инородческого образования в Казанском крае. Казань.

## БЕЗНЕҢ ТӨБӘК МӘГЪРИФӘТЧЕЛӘРЕ

***Закирова Гөлназ Илдус кызы,***
*Әгерҗе шәһәре 1нче гимназиясенең туган тел укытучысы*

Укытучы һөнәренә кызыксыну кимү, чыгарылыш сыйныф укучыларының педагогия уку йортларына ашыкмавы, укып чыкканнарының да мәктәптән читкәрәк китәргә тырышуы уйланырга мәҗбүр итә. Безнең халык элек-электән гыйлемгә омтылып яшәгән, укымышлы кешеләрне зурлаган, укырга яки укыганны тыңларга яраткан, китап сөйгән, китап сүзен хакыйкать сүзенә тиңләгән. Шушы максатны күздә тотып эшләнгән «Булачак укытучылар мәктәбе» электив курсы татар мәгарифенең юл башын, күренекле укытучылар эшчәнлеген Әгерҗе төбәге мәгарифе үсеше белән берлектә өйрәнеп, мәктәпләрдә үк укытучы һөнәре белән якынрак таныштыруны күздә тота.

Программаның яңалыгы – Әгерҗе төбәгендә татар мәгарифенә нигез салучылар, аның үсешенә җитди өлеш кертүче мәгърифәтчеләр, галимнәр, укытучылар эшчәнлеге турында мәгълүмат бирүдә.

Максат: укытучының һөнәри һәм шәхси хәрәкәтен күзәтеп, безнең төбәктән чыккан атаклы мәгърифәтчеләр эшчәнлеген өйрәнеп, укучыларның укытучы һөнәре белән кызыксынуларына ирешү.

Быел, Педагог һәм остазлар елында, укытучы, галим, профессор, мәгърифәтче якташыбыз Мөхетдин Корбангалиевың 150 еллык юбилее. Ул – 130 фәнни хезмәт, йөзгә якын дәреслек язган, орфографик, аңлатмалы, фәнни терминнар сүзлекләр авторы.

Мөхетдин Хафизитдин улы үз хезмәте турында болай ди: «... безнең бурычыбыз, милләтебезне артка калудан саклардай һәм милләтебезнең рухына ярдәм итәрдәй динле вә әхлаклы милләт балалары тәрбияләп чыгару». Бөек мәгърифәтченең бу сүзләре бүген һәр укытучының девизы булырга тиеш.

## ЯКУБ ХӘЛИЛНЕҢ ПЕДАГОГИК ЭШЧӘНЛЕГЕ

***Мурзина Гөлнара Фәрид кызы,***
*ТР ӘМР Әгерҗе шәһәре 1нче гимназиясенең*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Цифрлы укыту-методик комплектлары – эшчәнлегемдә ератып куллана торган бер чара. Миңа калса, телгә өйрәтүдә замана баласының игътибарын җәлеп итү өчен бик кулай алым. Бу эштә миңа www. storyjumper.

com конструкторы ярдәмгә килде. Интерактив китап – проектлар төзү өчен менә дигән шәп ысул.

Укучым Камалов Аяз белән берлектә төзегән интерактив китап Иж-Буби мәдрәсәсе шәкерте Якуб Хәлилигә багышланган, ул «Сиңа гына, халкым, хезмәтем» дип атала. Ни өчен интерактив китап әлеге шәхескә багышланган соң? Чөнки Якуб Хәлилинең бер канаты иҗади эшчәнлек булса, икенче канаты мәгърифәтчелеккә килеп тоташа. Бу китапта Якуп Хәлилинең иҗаты һәм татар мәгърифәтен үстерүгә керткән өлеше турында барлык мәгълүмат тупланган. Китап өч өлештән тора. Беренче өлештә аның тормыш юлы, гаиләсе турында әйтелә, балаларының фотолары бирелә. Икенче өлеш ул чыгарган, нигез салган «Сөембикә» журналын тасвирлауга багышлана, өченче өлештә исә Якуб Хәлилинең педагогик эшчәнлегенә басым ясала.

Бүгенге чорда татар педагогик фикерен өйрәнүдә иң төп принципларның берсе – аз өйрәнелгән, педагогика белеме киңлегеннән төшеп калган исемнәрне фәнни әйләнешкә кертүдән гыйбарәт. Моңарчы аз билгеле булган, төрле сәбәпләр (нигездә сәяси) аркасында күләгәдә кала килгән, онытылуга дучар ителгән татар педагоглары шактый. Тикшеренүчеләр алдында торган төп бурычларның берсе – XIX–XX гасыр башында яшәгән һәм татар милләтенә хезмәт иткән, китаплары һәм мәкаләләре фәнни әйләнешкә кермәгән, репрессияләр чорында хезмәтләре юк ителгән педагог-галимнәрнең, укытучыларның педагогик мирасын бүгенге заман укучысына җиткерү.

Нәтиҗә ясап әйтсәк, нинди генә чорда яшәсәк тә, бигрәк тә цифрлаштыру заманында бай тарихыбызны, үткәнебезне онытырга хакыбыз юк. Киләчәк буыннарга шул турыда язып калдыруны, тарихыбызны мәңгеләштерүне, якташларыбыз Бубилар күрсәткән юлдан алга таба баруны олы бурычым дип саныйм. Әлеге проект эше дә шуны күз алдында тотып эшләнде.

# ЯКТАШЫБЫЗ ИВАН СТЕПАНОВИЧ МИХЕЕВ – КҮРЕНЕКЛЕ УДМУРТ ХАЛКЫ МӘГЪРИФӘТЧЕСЕ

***Мусина Эльвира Муллахтәм кызы,***
*ТР КМР МББУБ «Пычак урта мәктәбе»нең тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы*
***Яковлева Светлана Иван кызы,***
*ТР КМР МББУБ «С. Ә. Әхтәмов исемендәге Манзарас урта гомуми белем бирү мәктәбе»нең мәктәпкәчә төркеме тәрбиячесе*

Кукмара – мәдәни, тарихи һәм әдәби мираска бай төбәк. Безнең туган ягыбыз-күп милләтле төбәк. Без бер-беребез белән тыгыз элемтәдә яшибез. Безнең тарихыбыз, әдәбиятыбыз, мәдәниятебез, гореф-гадәтләребез бер-берсенә бик якын. Туган якны өйрәнү-халык культурасының гасырлардан килгән традицияләрен, халыкның зур һәм матур эшләрен аңларга булыша.

Бөек татар мәгърифәтчеләр мирасында, татар милләтеннән булмаган галим, укытучы И. С. Михеевның фәнни хезмәтләре зур урын алып тора. Ул – педагог, тел галиме, эре методист, шактый күп дәреслекләр, кулланмалар авторы.

Иван Степанович Михеев – безнең якташыбыз. Удмурт милләтеннән булуга карамастан, ул кечкенәдән үк татар һәм рус телләрен өйрәнә, башка милләт вәкилләре белән аралашып яши һәм гомере буе рус, удмурт, татар, чуаш, мари халыкларының узара дус, тату, аралашып яшәүн теләп киләчәк буыннарга мирас итеп калдырган зур шәхес. Танылган галим, педагог турында Оштырма Юмья урта мәктәбендә удмурт балаларына татар теле укытканда таныштык һәм аның иҗатын өйрәндек.

Иван Степанович Михеев 1876 елның 19 июнендә Казан губернасы Мамадыш өязенең (хәзерге Кукмара районы) Оштырма-Юмья авылында туа. Ул Казан укытучылар семинариясендә укып бетергәч, иң беренче укытучылык эшен Вятка губернасы Мари Тюрюк өязенең Карлыган мәктәбендә башлый. КДУ рабфагына 1913 елларда рус теле укыта һәм Казан шәрык-педагогик институтында эшли. Шул елларда ул шәхси басмаханәсен булдыра, удмуртлар өчен китаплар һәм дәреслекләр әзерли.

Иван Степанович Михеев 1930 нчы елларда Урта Азиянең Самарканд, Ходжинск педагогик институтларында хезмәт итә. Аны өч елдан соң доцент дәрәҗәсенә күтәрәләр. Урта Азиядәге эшчәнлеге өчен Михеев Иван Степановичка Хезмәт Герое исеме бирәләр. Михеев наркомпро-

ска уку-укыту программаларының камил булмаганлыгын аңлата һәм яна дәреслекләр өстендә эшли башлый. Ул 1937 елның февраль аенда кулга алына. Аны совет властена каршы пропаганда алып баруда гаеплиләр һәм шул елны Михеевны атып үтерәләр. Иван Степановичны коммунистлар партиясенең XXнче съездыннан соң аклыйлар.

Иван Степановичның тормышы авыр булса да, ул халык өчен һәм студентлар, укытучылар өчен бик күп китаплар язган, дәреслекләр төзегән. Аның турында укыгач, мин аның туган ягын һәм халкын, телен яратуын аңладым. Ул халык өчен шундый кызыклы, файдалы киңәшләр язып калдырган!

Михеев Иван Степанович – Удмурт телендә милли мәдәниятне үстерү һәм туган телдә белем алу кирәклеге турында идеялар алып барыла торган пьесалар авторы («Удмурт табибы», 1920; «Удмурт укытучысы», 1924).

Ул рус телендә дәреслекләр төзегән, уку өчен китаплар, күнегүләр җыелмасы, грамматик күнегүләр, визуаль проблемаларының арифметик китабы, Удмурт праймеры, уку өчен беренче китап «Сөйләшү дәресләре» үткәрү өчен күрсәтмәләр һәм балалар өчен уку китаплары яза.

Михеевның «Удмурт дышетись» («Удмуртский учитель»), «Удмурт доктор»(Удмуртский доктор»), «Визьтэм Онтон»(«Бестолковый Онтон»), «Пелляскись»(«Знахарка») пьесаларын кешеләр бик яратып укыйлар. Хәзерге вакытта алар төрле телләргә дә тәрҗемә ителгән.

Удмурт телендә (1905-1910 елларда) үз хисабына ул еллык календарь китабы бастырып чыгарган. Михеевның календарьлары кешеләргә төрле мәгълүмат кенә түгел, ә файдалы киңәшләр дә биргән. Мәсәлән, календарьларда ул мәктәп балаларына түбәндәге киңәшләрен бирә:

– «Шонер гожъя» (Дөрес итеп яз!)

– «Гожъякуд шонер пук» (Язганда дөрес утыр!)

– «Муртлы шуг эн кары» (Кешеләргә начарлык эшләмә)

– «Уж сюдэ, азьтэмлык соры» (Хезмәт ашата, ялкаулык боза)

Календарьда балаларга белем бирү, тәрбия мәсьәләләре аерым урын алып тора. Балалар таза-сау булып үссеннәр өчен гаилә бердәм, тату булырга тиеш, дип саный галим. Кече яшьтән үк балалар өй эшләрендә катнашырга тиеш. Өлкәннәрне хөрмәт иткән, тыңлаган балага Михеев зур өмет баглый.

Михеев И. С. мәктәпкәчә яшьтәге балалар белән эшләүнең төп таләпләре -баланың психофизик үзенчәлекләрен көндәлек өйрәнү, исәпкә алу һәм тикшерү, аның табигый, «ирекле» үсешенә, мөстәкыйльлек, хезмәт күнекмәләрен формалаштыруга таяну бик мөхимлеген раслый. Ул шәхси

гигиенага, сәнгатьнең тәрбияви роленә, балаларны экскурсияләр һәм табигатьне «тере күзәтүләр» аша әйләнә-тирә мохитне өйрәнүгә җәлеп итүгә зур игътибар бирергә кирәк дигән фикерне тәрбиячеләргә, укытучыларга җиткерә.

Педагог баланы тәрбияләүдә әти-әнинең роле, туган тел аша башка телләрне өйрүнү, балаларны тормышка әзерләү уеннар аша булырга тиеш дип саный.

Иван Степановичның «Кеше күбрәк тел белгән саен күпмилләтле мохиттә аның аралашу культурасы да югарырак була, чөнки һәр тел артында халык һәм аның культурасы тора», – дигән фикере кызыклы. Безнең якташыбыз Иван Степанович үзенең эшләре һәм язмышы белән «интеллектуаль байлыйк» калдырган шәхес .

Танылган якташыбыз, телче, мәгърифәтче – И. С. Михеев педагогика үсешенә генә түгел, ә төрле милләтләр арасында дуслык элемтәләрен дә урнаштыруга зур өлеш керткән галим.

Хәзерге вакытта галимнең иҗатын, фәнни эшләрен өйрәнү– тәрбия өлкәсендә эшләүче укытучыларга, тәрбиячеләргә зур ярдәм булып тора. Иван Степанович Михеев иҗатын төрле яклап өйрәнү һәм аны саклап калу безнең бурычыбыз!

## ТАТАР ХАЛКЫНА БАГЫШЛАНГАН ГОМЕР

***Мөхәммәтдинова Гөлфия Габделбәр кызы,***
*ТР КМР МБГББУ «Чарлы*
*урта мәктәбе»нең татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Татар халкының күренекле галиме, мәгърифәтче, танылган педагог һәм методист, атказанган фән эшлеклесе, хезмәт каһарманы, орденлы профессор Мөхетдин Хафиз улы Корбангалиев 1873 елның декабрендә элекке Вятка губернасы, Алабуга өязе, Сарсак-Умга волостеның Биектау авылында ярлы крестьян гаиләсендә дөньяга килә. Үз авылларындагы рус-татар мәктәбен тәмамлагач, ул Казандагы татар укытучылар мәктәбенә укырга керә. Шул ук вакытта шәһәрнең алдынгы фикерле студентлары белән аралаша. Мөхетдин Корбангалиев Казан укытучылар мәктәбендә укыган вакытта Каюм Насыйри янына килеп йөри һәм аннан киңәшләр ала.

Укытучылар мәктәбен Мактау грамотасы белән тәмамлап, ул Мамадыш өязе Чирчи авылына укытучы итеп билгеләнә. Ул вакытларда авылда беркем дә баласын мәктәпкә укырга җибәрергә теләми. Мөхетдин Кор-

бангалиев, өйдән-өйгә йөреп, үгетләп, ата-аналардан балаларын мәктәпкә китерүләрен сорый. Мөхетдин Корбангалиев балаларны авылдан читкә китеп эшләүче ир-атларга хат язарлык русчага өйрәткәч, халыкның аңа ихтирамы арта, балаларны укырга йөртә башлыйлар.

1903 елның кезендә М. Корбангалиев Казандагы татар приютына медир һәм укытучы итеп күчерелә. Монда эшләгән вакытта ул Х. Ямашев, Г. Коләхмәтов кебек большевиклар белән таныша һәм алар белән бергәләп эшли башлый. Ул газета-журналларга мәкаләләр язу белән дә мавыгып китә. Казандагы татар яшьләре арасына кереп китеп, алар белән берлектә «Шәрык клубы» ачалар.

1905-1906 елларда Мөхетдин Корбангалиевның «Казан мөхбире», «Азат», «Азат халык», «Урал» газеталарында мәкаләләре дөнья күрә. «Азат халык» газетасында аның имзасы белән: «Хөкүмәт һәм чиновниклар халыкның дошманнарыдыр», – дип тәмамланган бер мәкаләсе басылып чыккач, цензура аны хөкемгә тарту белән дә куркыта. Сәяси тормышта катнашуы белән бергә, Мөхетдин Корбангалиев үзенең педагогик эшен дә алып бара.

Ул 1912-13 елларда ук башлангыч мәктәпләр өчен әлифбалар, арифметика дәреслекләре, уку китаплары һәм соңга табарак грамматика һәм география дәреслекләре төзеп бастыра. Урта мәктәпләр өчен грамматика китаплары, зурлар мәктәбе өчен әлифба һәм уку китаплары, татар башлангыч мәктәпләре өчен букварь һәм рус теленнән уку китаплары, шулай ук татар телен өйрәнүче рус һәм башка халыклар өчен махсус китаплар төзеп бастыра. Латин һәм рус графикасы нигезендәге алфавит һәм орфография кагыйдәләрен төзү эшендә башлап йөрүче ул була. Аның җитәкчелегендә русча-татарча һәм татарча-русча сүзлекләр төзелә.

1928-1940 елларда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире була. Төрле тип мәктәпләрдә укыту тәҗрибәсен файдаланып, ул методика өлкәсендә эшләүгә гаять тә күп көч куя. Аның «Ана телен укыту методикасы» (1918 ел), «Укырга-язарга өйрәтү методикасы» (1940 ел) үз вакытында бик кирәкле методик кулланма булып исәпләнәләр. М. Корбангалиев – татар теле орфографиясен эшләү буенча да зур хезмәт күрсәтә, рус графикасы нигезендәге алфавитка күчү буенча да актив эшли. Ул сүзлекләр төзү өлкәсендә дә күп хезмәт итә. Аның җитәкчелегендә русча-татарча һәм татарча-русча сүзлекләр төзелә. Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире буларак, барлык факультетларда да, студентларга татар телен укыту мәсьәләсен күтәрә. 1939 елда Ш. Рамазанов белән бергә татар теле алфавитын рус графикасына күчерүне тәртипкә сала. Мөхетдин Корбангалиев 1941 елның 3 июнендә Казанда вафат була.

Татар телен, татар халкын яратуы, хезмәт сөюе, ташып торган энергиясе һәм түземлелеге аңа барлык кыенлыкларны җиңәргә, үз юлыннан тайпылмыйча алга барырга, максатына ирешергә ярдәм итә. Ул ахыргы көненә кадәр татар халкын белемле итәр өчен хезмәт иткән, мәгариф, мәгърифәтчелек өлкәсендә, мәктәп-мәдрәсәләр ачуда, аларда татар телен укытуны кертүдә нәтиҗәле эшләгән. Мөхетдин Корбангалиевның эшен дәвам итеп, бүген безнең алдыбызда мәктәп-гимназияләребездә татар теле дәресләрен укытуны саклап калу бурычы тора.

## ФОРМИРОВАНИЕ РЕЧЕВЫХ УМЕНИЙ И НАВЫКОВ НА УРОКАХ УДМУРТСКОГО ЯЗЫКА И ЛИТЕРАТУРЫ

**Семенова Ангелина Пантелеевна**,
*учитель удмуртского языка и литературы,*
*русского языка и литературы*
*МБОУ «Ошторма-Юмьинская средняя школа» КМР РТ,*
***Семенов Виталий Геннадьевич,***
*учитель удмуртского языка и литературы,*
*МБОУ «Ошторма-Юмьинская средняя школа» КМР РТ*

**Аннотация:** в данной статье внимание уделено о необходимости поиска эффективных путей формирования языковой личности, действенных средств и методов работы по развитию речи, речевой культуры и речевого творчества. Считаем, что очень важно вызвать у детей интерес к слову, пробудить в них желание к развитию своей речи. Этот процесс продолжительный и требует от педагога чёткой организации своей деятельности, методической грамотности, практического опыта и системы. На уроках удмуртского языка и литературы необходимо научить детей пользоваться литературными словами, стремиться к развитию своей речи, как устной, так и письменной, совершенствовать своё речевое творчество.

**Ключевые слова:** культура речи; устная речь; письменная речь; связная речь; удмуртский язык; словарная работа; литературный язык.

Научить учащихся правильному пользованию родным языком является одной из важнейших задач общеобразовательной школы.

Эта задача осуществляется в процессе всей учебно-воспитательной работы на уроках и во внеурочное время. Так, получая знания из любой области науки, учащиеся знакомятся с новыми словами, терминами, оборотами. Эти знания обогащают мышление учащихся, совершенствуют их речь.

Но основные навыки пользования языком приобретаются учащимися в связи с изучением родного языка и литературы. Обучение на родном языке, считает Михеев, развивает речь и мышление ребенка. Мысль не может ни возникнуть, ни протекать, ни существовать вне языка, вне речи, то есть речь является средством мышления [3, с. 49]. Следовательно, в программах, как по родному языку, так и по литературе, уделяется большое внимание развитию речи.

Творческая работа помогает детям глубже осознать свои чувства, приучает к стройному, и последовательному мышлению, повышает самоуважение, развивает интерес к литературному творчеству. Дети рассказывают и пишут о самом интересном и близком, их сочинения развивают чувство коллективизма, повышают общественную активность.

Более всего способствует решению воспитательных задач целенаправленность раскрытия темы. Особенно удачными в этом смысле оказываются темы о труде, о школе, родном селе.

Сочинение воспитывает любовь к природе, к людям, к их труду и тому, что этим трудом создано, раскрывает красоту человеческих поступков и стремление подражать лучшим людям. Оно помогает детям осознать нравственные требования современности. Работа над творческой работой дает возможность совершенствовать речь школьников. Ученик должен уметь изъясняться на родном языке. Ведётся и подготовительная работа, которую проводит учитель: вместо литературных слов учащиеся часто используют диалектные слова. Так, зная, что детей может затруднить употребление некоторых слов в сочинении, чтобы предупредить речевые недочеты, проводятся специальные упражнения, направленные на обогащение речи учащихся. Особо акцентируем внимание на такие умения: умение исправлять, переделывать, улучшать написанное. Эти умения немыслимы также без развития у школьников языкового и стилистического чутья. Умение находить в своём сочинении отклонения от темы, отсутствие связи, непоследовательность в изложении мыслей – залог успеха в работе над сочинением.

За годы обучения в 5 – 11 классах учащиеся приобретают опыт связного изложения собственных мыслей. Устные рассказы и письменные сочинения проводятся в определенной системе. Особое место в этой системе занимают устные рассказы. Составляя их, учащиеся приобретают умение говорить связно, последовательно, правильно строить предложения, приучаются систематизировать, обобщать свои наблюдения, осмысливать свой жизненный опыт. Поэтому устные рассказы расцениваются не только как необходимые упражнения в развитии связной устной речи,

но и как подготовительные упражнения к сочинениям. Постепенно учащиеся усваивают, что в сочинениях можно не только рассказывать о событиях, но и оценивать дела и поступки людей, предметы, явления. Но чтобы ученику было о чем рассказать, необходима привычка вслушиваться, всматриваться в окружающий мир, умение чувствовать природу, видеть ее красоту. Эти качества приобретаются настойчивой систематической работой учителя и ученика. Наблюдательность детей следует развивать так же настойчиво, как мы развиваем дар слова. Учителю необходимо постоянно заботиться, чтобы у детей пополнялся запас жизненных наблюдений, накапливался личный опыт.

При правильной постановке творческая работа является эффективным средством воспитания, которая возбуждает эмоции, приучает детей осмысливать и оценивать виденное, пережитое, развивает наблюдательность, учит улавливать причинно-следственные связи, сопоставлять и сравнивать, делать выводы. Постепенно дети учатся выражать свои мысли и знания, все усложняющиеся и по содержанию и по форме. Обучаясь связной речи, школьники проходят путь от коллективных работ к самостоятельным, т. е. степень самостоятельности учащихся возрастает. Сочинение помогает детям глубже осознать свои чувства, приучает к строгому и последовательному мышлению, повышает самоуважение, развивает интерес к творчеству. Дети рассказывают о самом интересном и близком, их сочинения развивают и повышают активность, учатся понимать жизнь вокруг себя, а значит развивают личность в целом [2, с. 125].

Школьники любят писать сочинение на уроках, любят именно за его творческий характер за то, что в нем можно проявить самостоятельность, писать свое. Лучшие работы учащихся затем выразительно прочитываются в классе и становятся предметом анализа. Вначале мы читаем и анализируем удачное сочинение, подчеркиваем его содержательность, полноту раскрытия темы, указываем удачно найденные заголовки, затем подробно анализируем одно из сочинений с недочетами в раскрытии темы. Это тоже воспитывает. Лучшие работы отправляем в газету «Ӟечбур!» («Здравствуй!»). В газете всегда на первом плане стоят воспитательные задачи: уважение и любовь к труду, честность, дружба, уважение к старшим, помощь товарищу, хорошая учёба. Заметки, которые были опубликованы в газете «Ӟечбур!», экспонируются на стенде «Юнкорлэн сэрегез» в кабинете удмуртского языка и литературы. Это даёт возможность всем учащимся познакомиться с результатами работы товарищей.

Школа и газета вооружают своих воспитанников умениями, необходимыми в общественной жизни. Так, в школе учащиеся учатся писать

простейшие заметки в газету. От обычного сочинения заметка отличается краткостью, меткостью языка, а также тем, что в ней всегда остро ставится проблема, нередко содержится призыв, обращение к читателю.

В сущности, сочинения на самые разнообразные темы могут быть написаны как заметки в газету. Дети, поняв общественную пользу от своих сочинений, охотнее и серьезнее работают над ними.

**Литература**


1. Баринова Е. А., Адрианова М. Е. Развитие речи на уроках русского языка и литературного чтения. – Москва, 1959
2. Львов М. Р. Речь младших школьников и пути её развития. Пособие для учителей. М., «Просвещение», 1975. С. 125-126
3. Суворова З. В., Педагогические идеи удмуртского просветителя И. С. Михеева. Ижевск: Удмуртия, 1990. – 96 с.


## ОСТАЗ БУЛУ – БУ ҺӨНӘР


**Фатыйхова Руфия Мөэмин кызы,**
*ТР КМР МБГББУ «Березняк авылы Х. В. Ваһапов исемендәге төп гомуми белем бирү мәктәбе» укытучысы*


Заман алга бара дип чын күңелдән сөенәбез. Ләкин тирә-як мохит моңардан зыян гына күрүен онытып җибәрмәскә тиешбез. Промышленностьнең үсүе табигатьнең тигезлеген югалтуга китерде: сулыкларның, һава, җир өслегенең пычрануы кеше сәламәтлегенә куркыныч яный, бигрәк тә балаларга. Күп кешеләрдә экологик белемнәр һәм экологик культура җитеп бетми. Һичшиксез бу укыту-тәрбия эшенең җитешле дәрәҗәдә булмавы илебез халкына табигатькә карата дөрес караш формалаштыра белмәү нәтиҗәсе.

Соңгы елларда белем бирү оешмаларында экологик белем һәм тәрбия бирүгә игътибар артты. Киләчәк буынга экологик белем бирүдә мәктәп мөһим роль уйный.

Табигать белән аралашу хәзерге заман кешесенең иң зур мохтаҗлыгы булып санала. Ә бу аралашуны бала чактан ук тәрбияләргә кирәк. Боларның барсын да истә тотып 1994 елда безнең Березняк мәктәбенең география һәм биология укытучысы Нәбиев Рәсил Гәзиз улы «Кырмыска» балалар экологик хәрәкәтен оештырды.

**Хәрәкәтнең максаты:**

– әйләнә-тирәне яратучы, аңа сакчыл караучы социаль яктан актив, гуманлы иҗади шәхес тәрбияләү.

**Бурычлары:**

– туган як табигатенә сакчыл караш тәрбияләү;

– табигать күренешләре һәм бәйләнешләре турында күзаллауларны киңәйтү һәм системалаштыру;

– экологик белемнәрне пропагандалау.

**Эшчәнлегенең төрләре:** – гамәли эзләнү, әңгәмәләр, очрашулар, кичәләр, эзләнүләр, күргәзмәләр, кара – каршы сөйләшүләр, экскурсияләр.

**Эшчәнлекнең үтәлү вакыты:** 1994елдан – бүгенге көнгә кадәр дәвам итә

Нәбиев Рәсил Газиз улы, 1960 елда Татарстан Республикасының Тәкәнеш районы Ятмас Дусай авылында туган. 1977 елда Нырты урта мәктәбен тәмамлый. 1977-1978 елларда Түбән Арбаш мәктәбендә тәрбияче һәм музыка хезмәткәре булып эшли. 1978-1981 елларда Саба районының Лесхоз урта мәктәбендә озайтылган көн төркеме тәрбиячесе булып эшли. 1981-1983 елларда армиядә хезмәт итә. 1983-1984 елларда Ядегәр мәктәбендә физкультура һәм хезмәт укытучысы булып эшли. 1989 елда Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлый һәм география һәм биология укытучысы белгечлеген ала. 1989 елдан 2021 елга кадәр, лаеклы ялга киткәнче, Березняк урта мәктәбендә эшли. Лаеклы ялда булса да, күп еллар хезмәт куйган мәктәбе белән элемтәдә тора һәм минем өчен зур «Остаз»ым булым тора.

Рәсил Газиз улы республикада гына түгел, Россиядә дә «Кырмыска» балалар экологик хәрәкәтенең инициаторы, рухландыручысы булып тора. 1993 елда ул республикада беренче тапкыр Кукмара районы Березняк урта мәктәбе базасында «Кырмыска» балалар экологик хәрәкәте оештыра. Программа төзи, Устав төзи, экологик төркем эшчәнлегенең төп юнәлешләрен билгели. «Кырмыскалар» үз гимнын, антын, шулай ук үз традицияләрен булдыралар. Башкалардан аермалы буларак, «Кырмыскалар» төркеме ел дәвамында эшли. Табигатьне саклау һәм экологик эшчәнлектән тыш, «Кырмыскалар» шефлык эшен алып бара. Остазым төзегән программа буенча эш хәзерге вакытта дәвам итә.

«Кырмыскалар» эшчәнлеге, барыннан да элек, практик эш формаларының күптөрлелеге белән аерылып тора. Болар-кыр практикумнары, экспедицияләр, экологик сукмаклар булдыру һәм аларга хезмәт күрсәтү, дару чималы җыю, урман утырту, яшел патрульләр эше, мәктәп тыюлыгының торышын өйрәнү, чишмәләрне һәм урман массивларын санитар чистарту, экологик постлар оештыру, янгыннарны кисәтү максатларында урман массивларын патрульләштерү, экологик бәйрәмнәр, мәктәп тыюлыгында эшләү, табигый объектларны паспортлаштыру, саклау акцияләре.

1996 елдан Рәсил Газиз улы укучылар белән бергә «Рус тигезлеге Фенологиясе» темасы буенча Рус география җәмгыяте заказы буенча фәнни-эксперименталь эш алып бара. Эксперимент биология фәннәре докторы, Россия Фәннәр академиясе әгъза-корреспонденты А. А. Минин җитәкчелегендә РГО фенология комиссиясе тарафыннан төзелгән аерым методика буенча алып барыла. Эксперименталь эш – ел дәвамында фенологик күзәтүләр, тикшеренүләр үткәрү, эшләнгән эшләрне анализлау, нәтиҗәләрне алдагы еллар белән чагыштыру һәм Мәскәүгә фенологик мәгълүматлар җибәрү.

«Кырмыска» балалар экологик хәрәкәте эшчәнлеге «Россиядә балалар экологик хәрәкәте» кебек китапларда чагылыш тапты. [1]

Укытучы тарафыннан «Кырмыскаларның яшь экологлары елъязмасы»;» География һәм биология укытучылары өчен методик кулланма»;» Башлангыч сыйныф укытучылары өчен экология буенча белем бирү программасы»; «Татарстанның кече елгалары «Җәйге экспедициясе»; «Кырмысканың Уставы», «Кукмара районының экологик программасы»; «Кырмыскаларның «Практик табигатьне саклау эшчәнлеге»; «Кырмыскаларның «балалар экологик хәрәкәте», «Кырмыскаларның «Кечкенә ил», «Яшь эколог» һ. б.

Өстәмә экологик белем бирү буенча аның программалары авторлык программаларының һәм методик эшләнмәләрнең республика, Россия конкурсларында призлы урыннар алып торды.

Аның укучылары – район, республика һәм халыкара фәнни-тикшеренү конференцияләрендә җиңүчеләр. 1995 елда Рәсил Газиз улы җитәкчелегендәге «Кырмыска» экологик төркеме «Кырмыска» республика конкурсында грант җиңүчесе булды һәм төсле телевизор һәм видеомагнитофон, шулай ук ТР Мәгариф министрлыгы Дипломы белән бүләкләнде. Бу беренче һәм зур җиңү иде.

1997 елда Россия экологик конкурсы призеры була һәм РФ МБ Дипломы һәм Ордены белән бүләкләнә. 2006 елда Рәсил Газиз улы гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы иң яхшы укытучылар Бөтенроссия конкурсында җиңүче булды һәм Россия Федерациясе Президенты грантын алды. Ул шулай ук 2018 елда «Балаларга тәрбия һәм өстәмә белем бирү өлкәсенең иң яхшы хезмәткәре» грантына ия булды. 2019 елда ул «Экояз» республика конкурсында грант җиңүчесе булды һәм төсле принтер белән бүләкләнде.

2020 елда ул шулай ук «Тыюлык сукмаклары» республика конкурсында грант җиңүчесе булды һәм Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгыннан диплом һәм смартфон белән бүләкләнде.

Шулай ук аның экологик проекты ДЭД «Кырмыска» «EcoWorld – 2017» халыкара экологик конкурсында катнашты. Конкурс нәтиҗәләре буенча Рәсил Газиз улы «EcoWorld – 2017» Халыкара Экологик Премиясе лауреаты булды һәм академик В. И. Вернадскийның «РАЕН үсешенә өлеш керткән өчен» медале белән бүләкләнде. Бүләкләү тантанасы РФ Дәүләт Думасында узды.

Рәсил Газиз улы туган як тарихы белән мавыга. Архив, тарихи, туган якны өйрәнү материалларын җыя һәм Россиянең төрле югары уку йортлары, фәнни җәмгыятьләре галимнәре, археологлары, геологлары, тарихчылары белән тыгыз хезмәттәшлек итә. Туган якны өйрәнү темаларына докладлар белән чыгыш ясый. 2019 елда «Ятмас Дусай авылы тарихы» китабын нәшер итүе эшнең нәтиҗәсе булып тора. 2022 нче елда Рәсил Газиз улы «Кукмара муниципаль районы каршындагы казанышлары өчен» медале белән бүләкләнде.

2020 елда Березняк мәктәбендә «Стебелек (Бәбәк)» мәктәп урманчылыгы оештырылды. Бу эшне дә остазым башлап җибәреп, ңәтиҗәле эшләп миңа тапшырып китте. Мәктәп урманчылыгы составында 15 укучы. Алар 5-8 класс укучылары. Урман хужалыгы министрлыгы жибәргән план нигезендә мәктәп урманчылыгының да еллык эш планы төзелде, үз почмагы булдырылды. Эш планы нигезендә җыелышлар, мероприятиеләр уздырылып килә. Мөһим экологик даталар билгеләнеп уза.

Нәтиҗә ясап шуны әйтәсем килә: остазымның эшләгән эшчәнлеген барысын да санап бетерү мөмкин түгел. Барысы өчен дә ихлас күңелемнән рәхмәтемне белдерәм. Рәсил Нәбиевны бик күп укучылары үзләренең хезмәт җимешләре, яулаган үрләре белән сөендереп торалардыр, моның шулай икәнлегенә минем иманым камил. Шулар арасында минем үземнең дә булуым, бигрәк тә куанычлы. Хәзер вакытта эшемне намус белән башкаруымны дәвам итәм.

Язмамны Лена Шагыйрьҗанның шигъри юллары белән тәмамлыйсым килә:

*Җир йөзендә иң-иң матур теләкләрне*
*Сорасалар, багышларга кемгә, дип,*
*Үзенә бик күп йөрәкләрне әсир иткән*
*Укытучы, дияр идем, башым иеп.*

[1] Түбән. Новгород. Басма. Ю. А. Николаев, 2005. – 244 с., «Рус тигезлеге Фенологиясе: материаллар һәм гомумиләштерү». Мәскәү. АВФ, 2000. 160-Сан.

# РИВАЯТЬКА ТИҢ ГОМЕР

***Хабибуллина Райса Харисовна,***
*ТР Казан шәһәренең Һ. Такташ исемендәге*
*27нче гимназиясенеңгеография укытучысы;*
*өстәмә белем бирү түгәрәге педагогы*
***Борханова Ляйсан Рафисовна,***
*ТР БМР МБГББУ Нөнәгәр урта мәктәбе»нең*
*башлангыч сыйныфлар укытучысы*

Кем ул остаз? Ул – үзеңдәге белемне һәм тәҗрибәне башка кешегә тапшыручы, билгеле бер өлкәдә зур уңышка ирешкән, осталыкка һәм тәҗрибәгә ия булган кеше. «Остаз – өйрәтүче, укытучы, җитәкче. Профессорны да «остаз» дип атау кабул ителгән. Татарча оста (мастер) сүзе шул тамырдан. Элегрәк бу төшенчә балта остасын гына белдерә, соңыннан, һөнәрнең башка тармакларына да күчеп, гомумән, «мастер» мәгънәсен аңлата». (Адлер Тимергалин. «Миллият сүзлеге: аңлатмалы сүзлек», 2том. ). Беренче профессиональ хатын-кыз режиссёр, актриса, педагог, татар радиосында диктор, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Кәшифә Тумашева-күпләр өчен остаз. Аның яшәү кыйбласы, тормышы театр, сәнгать дөньясы белән бәйле. Ул – күпләрне көнләштерерлек мактаулы гомер юлы узып, татар театр сәхнәсендә якты эз калдырган шәхес. Аның өчен бәхет – сәхнә, ә сәнгать – газиз халкына хезмәт итү була.

Кәшифә Җамалетдин кызы Тумашева 1903 елның 7 гыйнварында Балтач районының Нөнәгәр авылында туа. 5 яшьлек сабыйга бик иртә аерылу сагышын кичерергә туры килә. Себердә яшәүче тутасы белән җизнәсе Кәшифәне үзләренә алмашчы булыр дигән ният белән ерак Өркет каласына алып китәләр. Әтисе дә кызын укыр, эшкә өйрәнер дип ризалыгын бирә. Җизни белән тутасы Кәшифәнең зирәклеген күреп алалар. 1910 нчы елда якшәмбе мәктәбендә, соңарак җәдиди кызлар мәдрәсәсендә укыталар. Мәдрәсәне бик яхшы билгеләренә тәмамлый. Кәшифәнең бик тә укытучы буласы килә. Туганнары каршы булсалар да, гимназиягә кереп, аны да уңышлы тәмамлый. Өркет мәгариф мәдәният җәмгыяте Нөнәгәр кызын Төркиягә университетка укырга җибәрмәкче була. Әмма, укытучы булырга хыялланган кызның юлына гражданнар сугышы киртә була. Колчак гаскәрләре җиңелеп, Өркеттә Совет власте урнаштырылгач, беренче мөселман театр труппасы оештырыла.

Язмышны узып, каршылыкларны җиңәргә өйрәнеп барган кызның йөрәгендә ялкын кабына: авыл кызы кыюлыгын җыеп, сәхнәгә менә. Яз-

мыш аны татар труппасы режиссёры Рәхим Тумашев белән очраштыра. Труппаның талантлы артисткасы булып Себер киңлекләрендә «Зауральская» кушаматы белән танылa.

1921 ел. Мәгариф бүлеге Семипалат шәһәрендәге мәдәният йорты каршында профессиональ татар театр труппасы оештырыла. «Мине ирем Рәхим белән шушы театрга чакыртып алалар. Ләкин мин моңа гына канәгать түгел: мине туган ягым, әти-әни яшәгән ягым тарта. Үзем сәхнәдә, ә күңелем белән мин Казанда. Режиссёр булырга иде дигән теләгем бар нәрсәдән дә көчлерәк. Укырга, белем алырга һәм режиссёр булырга, Казанга кайтырга кирәк! Мин бит татар кызы! Үз милләтемә, үз халкыма хезмәт итүне максат итем куйдым», – ди Кәшифә Тумашева («Казан утлары» журналы, 1980 ел, №3).

20 яшьлек Кәшифә ире Рәхимҗан белән, 3 айлык уллары Равилне алып, Казанга кайталар. Ул Казан театр техникумының 2нче курсына кабул ителә. Илдә ачлык, хәерчелек хөкем сөргән чор булу сәбәпле, техникумны 73 укучының 22сенә генә тәмамлап чыга ала. Алар арасында Кәшифә Тумашева, Риза Ишморат, Хәким Сәлимҗанов һәм башка сәхнә йолдызлары була. Кәшифә Тумашева техникумда педагог – режиссёр итеп калдырыла, бик тиздән остаз-педагог булып та танылa. Укыту дәверендә аңа ассистент һәм режиссёр эшләре дә йөклиләр. Ерак авыллардан килгән егет-кызларга үтә дә игътибарлы була. «СССР ның халык артисты Шәүкәт Биктимеровның Әлмәндәре «Банкрот»тагы йомышчы малайдан үсеп китте. Кәшифә апа аны күрде һәм күтәреп алды, җиңәчәгенә ышанды» (Госман Әхмәтҗанов истәлекләреннән). «Кәшифә апа безне сәхнәдә уйнарга гына түгел, үз-үзеңне ничек тотарга, ничек сөйләшергә, уйларга һәм яшәргә дә өйрәтте» (Татарстанның атказанган артисты Кәримә Нуруллина истәлекләреннән).

XX гасыр башы. Татар халкын таң калдырган могҗиза-татар радиосы эшли башлый. Кәшифә Тумашева радиога диктор һәм режиссёр итеп чакырыла. Ул – татар сүзен эфирга чыгаручы беренче диктор һәм радио эшен камилләштерүгә үзеннән зур өлеш керткән шәхес.

Педагог, радиода диктор, артистка. Кәшифәгә югары белемле режиссёр булу теләге тынгылык бирми. 1932 елда Мәскәүгә ГИТИСның режиссёрлык факультетына укырга китә. Тормыш аңа тагын бер сынау әзерли. Кинәт ире Рәхим вафат була. Аңа тормышын жайлап җибәргәнче укуын калдырып торырга туры килә. Кабат радиога эшкә кайта, шул ук вакытта үзешчән сәнгать түгәрәкләренә җитәкчелек итә. 1933 елда колхоз-совхоз театрлары оештырыла. Кәшифә Тумашева Балтач театр коллективын җитәкли.

Авыл кызы язмышына буйсынып, ярты юлда туктап калыр кебек. Көчле ихтыярлы Кәшифә ике сабыен үзе белән Мәскәүгә алып китеп, укуын дәвам итәргә карар кыла. Ниһаять, Кәшифәнең укуы тәмам. «Күзләр» спектакле аның диплом эше була. Ул Казанга кайта һәм Галиәсгар Камал исемендәге академия театрында режиссер итеп билгеләнә. Татар Академия театры сәхнәсендә 15 ел эчендә 30га якын спектакльләргә җан өргән соклангыч режиссёр булып танылa. Дәрәҗәле, көчле-куәтле ир-егетләр белән беррәттән сәхнә тоту аңа җиңел булмый. Тормыш кануннарын тирәнтен аңлавы, тамашачы күңеленә хуш килерлек җыр-бию сайлавы, киемнәргә, сәхнә бизәлешенә нык игътибар итүе белән артистлар күңеленә юл яра. «Күзләр» һәм «Хуҗа Насретдин» спектакльләре Кәшифәгә зур танылу китерә.

1955 елда Кәшифә Тумашеваны республика күчмә театрына баш режиссёр итеп күчерәләр. 1955 – 1962 еллар арсында төрле темаларга 30 дан артык яңа спектакль куелган.

Нөнәгәр кызы бар белемен, талантын, көчен театрның яшь көчләрен тәрбияләүгә бирә. Театрны яратып, иҗатларын, хезмәтләрен халыкка багышлаган дәвамчылар халык ихтирамын, мәхәббәтен яулаган артистлар әзерли. Фердинанд һәм Люция Фарсиннар, Гата һәм Кәримә Нуруллиналар, Сания Исмәгыйлева, Ринат Мифтахов, Әнәс Галиуллин, Исламия Мәхмүтова, Роза Җиһаншиналар һ.б күпләр халык ихтирамын, мәхәббәтен яулаган артистлар. Бу урында Татарстанның халык артисты Әнәс Галиуллинның истәлекләрен әйтеп китү урынлы булыр: «Мин Кәшифә апа белән берничә ел эшләдем. Аның белән бергә иҗат итү – үзе бер могҗиза иде. Кәшифә апаның бөтен тәрбиясе эш вакытында булды. Аның дәресләре гомерем буена җитте. Ул үзен һәрвакыт гади итеп тота, кешенең хәленә кереп, мөмкин булганча булыша иде».

Кәшифә Тумашева – бәхетле кеше. Аның театрга тугрылыгын саклап, иҗатта янып яшәрлек дәвамчысы – улы, режиссёр, педагог, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Равил Тумашев бар.

Кәшифә Тумашеваның театрны үстерүдәге олы хезмәте югары бәяләнә. 1956 елда аңа Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исем бирелә. Театрның гомере спектакль игъланнарындагы сезон саны белән исәпләнә, диләр. Ә режиссёр гомере? Режиссёрның иҗат гомерен кешенең күнеленә салган мәхәббәт, тирәбездәге яхшы кешеләр саны белән исәплӛү дөрестер. Кәшифә, Равил Тумашевлар үзләреннән соң иң кыен чорда да сәхнәне ташлап китмәслек шәкертләр тәрбияләп калдыра алдылар.

Нөнәгәр авылы халкы элек-электән театр сәнгатен яраткан. Театрны якын итүебезнең сере шунда: анда безнең авылдашыбыз Кәшифә эзләре бар, анда ярты гасырга якын авыл сәхнәсендә якты образлар тудырган үзешчән авылдашларыбыз, бүген дә милләт өчен янып яшәүче үсеп килүче яшь буын бар. Авылыбыз үзешчәннәре тарафыннан авыл, тирә-юнь сәхнләрендә уйналган спектакльләр халыкчан, артистларның җанлы уеннары белән аерылып тордылар. 20 сәхнә әсәре уйнап, 200ләп образ тудырдылар:

Авылдан елап чыгып киткән Кәшифә 90 елдан соң кабат Нөнәгәр авылына әйләнеп кайта. Авыл халкы аның 95 еллыгын авыл мәдәният йортында зурлап билгеләп үтә. Тантанада Кәшифә Тумашеваның барлык хезмәтләре музейда сакланырга һәм ул музейның Нөнәгәрдә булырга тиешлеге турында әйтелә. Бүген Кәшифә Тумашева исемендәге мәктәп музее булу нинди зур сөенеч.

Авылыбызда татар театры халкыбызның милли традицияләрен югалтмыйча, шул ук вакытта сәхнә сәнгатебезне заманча яңа эстетик алымнар белән баетып иҗат итүче бер коллектив булып яши икән, димәк, Кәшифә апаның эше дәвам итә, аның иҗади рухы безнең арада, остазыбыз безнең белән.






# ФАТИХА АИТОВА МӘКТӘБЕ

***Хәлимова Руфия Раниф кызы,***
*ТР КМР МБГББУ « Чарлы урта белем*
*бирү мәктәбе»нең туган (татар ) теле укытучысы*

Безнең халыкка борын-борыннан хас сыйфатларның иң күркәме – белемгә мәхәббәт, гыйлемгә ихтирам. Мәктәп ачу, мәдрәсә тоту традицияләре гасырлар аша килгән. Россия империясенең законнары буенча мөселман уку йортларына, мәктәп-мәдрәсәләргә дәүләт казнасыннан бер тиен дә акча бирелмәгән. Мәктәпләр бары тик байлар һәм мәхәллә халкы хисабына гына яши алганнар. Халыкның аң-белемгә омтылышын күреп, татар байлары яңа мәктәп-мәдрәсә ачу өчен акча кызганмаганнар.

Татарлар арасында мәктәп-мәдрәсәләр шактый күп ачылса да, монда нигездә ир балалар гына белем алганнар. Аерым кызлар (күпчелек бай кызлары) гына әтиләреннән, абыйларыннан сабак алганнар. Кызлар мәктәп-мәдрәсәләре ачылу XIX гасыр азагы – XX гасыр башларына туры килә. Бу чорда җәдидчелек хәрәкәте көчәя. Җәдидчеләр мәктәпләрендә яңача укыту ысулларын гына кертеп калмыйлар, алар кызларны укытуның милләт өчен зарурлыгын да дәлиллиләр. Кызлар мәктәбенә беренчеләрдән нигез салучылар да җәдид муллалар, абыстайлар, я булмаса, аларның кызлары, уллары була.

Казанда ир балалар өчен беренче җәдит мәктәбен 1889 елда күренекле мулла һәм мөдәррис Галимҗан Баруди ачса, кызлар өчен беренче мәктәпкә 1890 елда аның хатыны Маһруй абыстай нигез сала.

Иганәче, җәмәгать эшлеклесе, татар халкына дөньяви белем бирү тарафдары Фатиха Габделвәли кызы Аитова (1866-1942) – халыкка аң-белем таратуда, мәктәп-мәдрәсәләр ачуда зур тырышлык куйган фидаи затлардан. Ул, беренчеләрдән булып, Казанда башлангыч училищелар программасы буенча эшләүче мөселман кызлары гимназиясе ачу кирәклеге мәсьәләсен күтәреп чыга.

Ф. Аитова 1866 елның ноябрендә Оренбург губернасының Троицк каласында сәүдәгәр Габделвәли Яушев гаиләсендә дөньяга килә. 1897 елда Казан сәүдәгәре Сөләйман Аитовка кияүгә чыга. Тарих фәннәре кандидаты Т. Биктимерова үзенең «Татар хатын-кызлары мәгърифәт юлында» дигән китабында билгеләп үткәнчә, «Фатиха кияүгә чыкканда үзенә гаиләдән бирелгән малны кызлар мәктәбе ачуга сарыф итү белән генә чикләнмичә, мәктәпне милли кызлар гимназиясе дәрәҗәсенә кадәр үстерә».

Фатиха Аитованың иң зур хыялы – милли кызлар гимназиясе ачу була. 1910 елда ул әтисе вафатыннан соң калган мираска дүрт сыйныфлы

дөньяви мәктәп ачтыра. Ул 1913 елда – алты сыйныфлы мәктәп, ә 1916 елда кызлар өчен беренче хосусый гимназия итеп үзгәртелә. Фатиха Аитова 1916 елның 4 мартында «Казанда мөселман кызлар өчен хосусый урта уку йорты ачарга» рөхсәт алуга ирешә. Ф. Аитова оештырган гимназия укыту эшләре куелышының һәм укытыла торган фәннәрнең рус мәктәпләренекенә туры килгән бердәнбер уку йорты була. Ул татар кызларының дөньяви белем алуга булган ихтыяҗына тулысынча җавап бирә.

Мәктәп укучылары да, укытучылар да дәресләргә махсус киемнәрдә йөрергә тиеш була. Укучыларның көндәлек киеме – ак якалы коңгырт кызыл төстәге . күлмәк, кара алъяпкыч, алсу каймалы ак яулык; бәйрәмнәрдә – ак алъяпкыч, ә өлкән кызларга нәфис калфак кию тәкъдим ителә. Укытучылар Европа модасы белән тегелгән ак челтәр якалы куе зәңгәр төстәге күлмәк һәм энҗеле калфактан йөргәннәр.

Анда укыган өчен түләү гаиләнең матди хәленнән чыгып билгеләнгән. Әлеге мәктәптә 30-40 кыз бала бушлай укыган. Шунлыктан гимназияне тотуга киткән чыгымның яртысын Ф. Аитова үзе түләгән. Ләкин шәһәр думасының мәктә пләр комиссиясе дә ел саен мәктәпкә 600 сум бүлеп биргән.

Тагын шунысы кызыклы: әлеге гимназиядә укыту-тәрбия эшләре җәдит мәктәпләре үрнәгендә алып барылган. Уку йорты шактый гына кыенлыкларга да очрый: мондый типтагы белем учагы өчен билгеле бер программа булмый. Шуңа күрә Ф. Аитова рус мәктәпләре өчен әзерләнгән программаны татар гимназиясе таләпләренә җайлаштырып төзи.

Кызлар гимназиясендә татар һәм гарәп телләре, рус теле һәм әдәбияты, гомуми тарих һәм Россия тарихы, гомуми география һәм Россия географиясе, арифметика, табигать белеме, кеше анатомиясе һәм физиологиясе, гигиена, педагогика, татарча һәм русча матур язу, рәсем, кул эшләре һәм дин гыйлеме укыту каралган. Россия тарихы һәм географиясеннән кала, барлык фәннәр татар телендә укытылган. Арифметикага атнасына – 3, рәсемгә – 2, Коръән нигезләрен өйрәтүгә 4 сәгать вакыт бирелгән.

Казан губернасы, халык училищелары директоры М. Пинегин карары нигезендә, кызлар гимназиясендә кием кисү һәм тегү, шулай ук ашсу әзерләргә өйрәтү курслары ачыла. Уку елы тәмамлагач Фатиха ханым укучыларын я киного, я үзләренең дачаларына кунакка алып бара торган була. Кызларны дачага алып чыгу өчен (193 укучы) Ф. Аитова бөтен Казан байларын җәлеп итә. Моның турында «Йолдыз» газетасының 833 нче санында языла.

Укыту-тәрбия эше шул заманның алдынгы педагогы Маһруй ханым Мозаффария (1873-1945) һәм махсус әзерлекле хатын-кыз мөгаллимәләр җитәкчелегендә алып барыла. 1916-1917 уку елында, мәсәлән, рус телен, русча матур язуны – Казандагы хатын-кызлар югары курсларын тәмамлаган Бибимәрьям татарча матур язу һәм табигать белемен – Шумкова гимназиясен тәмамлаган Мәрьям Мөштәриева, география һәм татар тарихын – Котова гимназиясендә белем алган Мәдинә Сәгыйтова, ә кул эшләрен гаилә укытучысы исеменә ия булган Вера Матвеева укыта. Гимназия 1918 елга кадәр эшли. Ул Казанда татар балаларына Европа мәгарифе үрнәгендә белем бирүче бердәнбер уку йорты була. Соңрак Совет власте тарафыннан ул беренче һәм икенче баскыч мәктәп итеп үзгәртелә.

Бу уку йортларын тәмамлап чыгучыларның күпчелеге я әдәбиятка, я сәнгатькә, я журналистикага юл алган һәм шәкертләрнең иң зур өлеше халыкка аң-белем тарату, хезмәт итүгә җиң сызганып керешкән. Милләт кызларын аң-белемле итүдә башлап йөргән бу якты шәхеснең исеме онытылырга тиеш түгел.

# СЕКЦИЯ IV

# ТВОРЧЕСКОЕ НАСЛЕДИЕ ЧИНГИЗА АЙТМАТОВА В ПЕДАГОГИЧЕСКОМ ПРОЦЕССЕ

## ВОСПИТАНИЕ ДУХОВНО-НРАВСТВЕННЫХ ЦЕННОСТЕЙ ШКОЛЬНИКОВ НА ПРИМЕРЕ ОБРАЗА МАТЕРИ В ТВОРЧЕСТВЕ ЧИНГИЗА АЙТМАТОВА

***Гайсина Рузалия Нургаяновна,***
***Николаева Эльвира Николаевна,***
*учителя начальных классов*
*МБОУ «СОШ с. Манзарас» КМР РТ*

